• ВАКЫЙГА •
ТАТАР ТЕЛЕ КУРСЛАРЫ БАШЛАНДЫ
*2 бит*

• КЫЙССА •
НУХ ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КЫЙССАСЫ
*5 бит*

• МӘҮЛИД •
МӘҮЛИДҮН-НӘБИ БӘЙРӘМЕ ХАКЫНДА
*10 бит*

• ҖӘДВӘЛ •
«АЗАН»РАДИОСЫ ПРОГРАММАСЫ
*15 бит*

*№ 10 (291)* *Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте басмасы* *Сафәр 1441*

*Октябрь, 2019*

دين ومعيشت

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

# Мәскәүдә «Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә» басмасы тәкъдим ителде




*Дәвамы 8 нче биттә*

# Татар теле курслары башланды

15нче октябрьдә Татарстанның 16 шәһәрендә һәм районында татар телен өйрәнү буенча мәчет каршындагы курслар рәсми рәвештә башланып китте.

Быел татар теле курслары 20 мәйданчыкта, шул исәптән республиканың 15 мөхтәсибәтендә – Әгерҗе, Әлмәт, Бөгелмә, Буа, Югары Ослан, Алабуга, Яшел Үзән, Лениногорск, Лаеш, Менделеевск, Яр Чаллы, Түбән Кама, Норлат, Чистай, Ютазы мөхтәсибәтләрендә үткәреләчәк. Башкалада курсларны «Ризван», «Тынычлык», «Казан нуры», «Гаилә» мәчетләрендә, шулай ук Россия ислам институтында тыңларга мөмкин.

Шунысын билгеләп узарга кирәк: иң күп санлы төркем – барлыгы 45 кеше татар телен нәкъ менә Россия ислам институтында өйрәнәчәк. Башкаланың «Казан нуры» мәчете дә әйдәп баручылар рәтендә – 35 кеше. Татарстан шәһәрләре һәм районнары арасында Түбән Кама мөхтәсибәтендә яшәүчеләр аеруча активлык күрсәтте. Биредә 30га якын кеше татар телен өйрәнергә теләк белдергән. Лидерлар рәтендә шулай ук Яр Чаллы (23 кеше) һәм Бөгелмә (20 кеше) мөхтәсибәтләре. Шулай да, төгәл саннар соңрак, төркемнәр тулысынча формалашып беткәч, билгеле булачак.

Дәресләрне атнага ике тапкыр уздыру планлаштырыла. Укыту курсы 48 академик сәгатькә исәпләнгән, аның дәвамлылыгы ярты елны тәшкил итәчәк (2019 елның 15 октябреннән 2020 елның 30 апреленә кадәр). Дәресләрне үткәрү вакыты курсларга йөрүчеләрнең теләген исәпкә алып билгеләнәчәк.

Интенсив курс программасы татар теленең сөйләм дәрәҗәсен өйрәнүгә, ситуатив лексик җыелмаларны үзләштерүгә һәм аралашу күнекмәләрен үстерүгә юнәлдерелгән. Моннан тыш, телгә булганнарга ислам дине мәдәнияте белән танышу, шулай ук тәҗвид кагыйдәләрен өйрәнү өчен өстәмә мөмкинлек каралган.

Дәресләрне югары белемле филологлар, тәҗрибәле татар теле укытучылары алып барачак. Укыту процессында ТР мөселманнары Диния нәзарәте һәм «Хозур» нәшрияты тарафыннан Россия ислам институтының татар теле һәм милли мәдәният кафедрасы белгечләре белән берлектә әзерләнгән «Татар теле. Башлап өйрәнүчеләр өчен» дәреслеген файдалану күздә тотыла.





Татар теле курслары бушлай. Укыту процессы тәмамлангач, тыңлаучыларга тиешле сертификат тапшыру күздә тотыла.

■ dumrt.ru

# «Хозур» нәшрияты «Россия мөселманнарының дини мирасы» I Халыкара форумында

14нче октябрьдә Болгар ислам академиясендә «Россия мөселманнарының дини мирасы» I Халыкара форумы үз эшен башлап җибәрде. Чара Россия мөселман халыкларының традицион ислам рухи кыйммәтләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча актуаль мәсьәләләр турында фикер алышу, аларны хәл итү максаты белән үткәрелә. Форум эше кысаларында ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты мөселман әдәбияты күргәзмәсен ачты.

«Хозур» нәшрият йорты стендында Татарстан мөфтияте тарафыннан татар, рус һәм гарәп телләрендә бастырылган 60 тан артык уку һәм агарту әдәбияты, мәдрәсәләр, югары уку йортлары, имамнар өчен укыту һәм методик әсбаплар, киң катлам укучылар өчен ислам традицияләрен һәм гореф-гадәтләрен аңлатучы фәнни-популяр китаплар тәкъдим ителә. Аерым алганда, күргәзмәдә классик дини хезмәт – күренекле татар дин галиме һәм мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗанинең алты томлык сайланма хезмәтләре җыентыгы урын алган иде. Галимнең әлеге җыентыгы үз эченә танылган «Хакк әл-мөбин фи мәхәсин әудаг әд-дин», «Хизәмәт әл-хәвәши лиидәхәт әл-гавәши», «Мөстәфәд әл-әхбәр фи әхвәл Казан вә Болгар», «Нәзурател-хак фи фәридатилгыйшәэи вә ин ләм йагыйбиш-шәфәкъ», «Китаб әл-хикмәт әл-бәлига әл-җәниййә фи шәрех әлгакаид әл-хәнәфиййә», «Китаб әл-фәваид әлмөхиммә» китапларын туплаган. Моннан тыш, күргәзмәгә килүчеләр бөек галим Әбү Мансур Әл-Матуридиның фундаменталь хезмәте – «Китаб әт-тәүхид» басмасы белән таныша ала. Анда Аллаһы Тәгаләнең берлеге, сыйфатлары, пәйгамбәрлек, тәкъдир, иман мәсьәләләре бәян ителә. Шулай ук стендка күптән түгел рус телендә дөнья күргән китаплар: «Имам Акмаледдин Әл-Бабиртиның имам Әбү Хәнифәнең «Васыят»енә («Әл-Васыя») шәрехе» һәм Әхмәт Биджанның «Әнвәруль-гашыйкин» («Светоч любви») хезмәтләре куелган иде.




ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты – Россиядә иң зур мөселман медиахолдингларының берсе. Эшләү дәверендә нәшриятта 500 мең данәдән артык тираж белән татар, рус һәм гарәп телләрендә 200 исемдәге китап дөнья күрде. Басмаларның төп өлеше (гомуми санның яртысына якыны) классик мөселман һәм татар дини-илаһият мирасына караган хезмәтләрдән гыйбарәт. Алар арасында Әбү Хәнифә, Матуриди, Тахави, Әл-Газнави, Ш. Мәрҗани, Р.Фәхретдин, К.Насыйри, Ә.Максуди, Г.Карабаш һ.б. авторларның хезмәтләре бар.

■ dumrt.ru

# Яшьләр мохитендә радикализмны профилактикалау

## ТР мөфтие «Яшьләр мохитендә радикализмны профилактикалау» дип исемләнгән Рәсәй – Алман иле семинары делегатлары белән очрашты



15 нче октябрьдә ТР мөселманнары Диния нәзарәте резиденциясендә яшьләр белән эшләүче белгечләр өчен үткәрелгән «Яшьләр мохитендә радикализмны профилактикалау» Рәсәй – Алман иле семинарында катнашучылар булып китте. Семинар 2019 елга Рәсәй – Алман иле яшьләр алмашу программасын гамәлгә ашыру кысаларында уза. Чара РФ Фән һәм югары белем министрлыгы, МИРЭА – Россия технология университеты, «Рәсәй – Алман иле яшьләр алмашу» фонды тарафыннан Рәсәй Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институты, «Милли-конфессиональ тикшеренүләр, экстремизмны профилактикалау һәм терроризм идеологиясенә каршы тору үзәге» Урал ассоциациясе һәм Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе ярдәме белән оештырылды. Форум Мәскәүдә Рәсәй Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институты базасында ачылды һәм Казанда дәвам итте.

Татарстан мөфтияте резиденциясендә 35 кешелек делегация Рәсәй һәм Алман иленең төрле почмакларыннан җыелды: Санкт-Петербург, Алтай, Ставрополь, Калининград, Дагыстан, Берлин, Гамбург, Кель, Бохум, Гёттинген һәм башкалар. Кунакларны Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, аның мәгариф буенча урынбасары һәм РИИ ректоры Рафикъ хәзрәт Мөхәммәтшин, мөфтинең мәгълүмати сәясәт буенча киңәшчесе һәм «Хозур» нәшрият йорты директоры Ришат Хәмидуллин һәм ТР Фәннәр академиясенең Ислам тикшеренүләр үзәге директоры Ринат Патеев каршы алды.

Республика мөселманнары башлыгы Диния нәзарәтенең яшьләр сәясәтен тормышка ашыру, киң җәмәгатьчелеккә, яшүсмерләр һәм яшьләр аудиториясенә юнәлдерелгән социаль активлык тәҗрибәсе белән уртаклашты, шулай ук Татарстанда конфессияара һәм милләтара тынычлык традицияләре турында сөйләде. Камил хәзрәт, беренче чиратта, мөфтият эшчәнлегенең төп юнәлешен билгеләп үтте:

– Безнең күпкырлы эшчәнлегебез кешеләр аңында «Ислам һәм экстремизм, радикализм, терроризм» ассоциацияләр рәтен юкка чыгаруга юнәлдерелгән. Үзебезнең эшебез белән без Исламның белемле, югары әхлаклы, толерант, актив гражданлык позициясенә ия, рухи һәм физик яктан сәламәт кешеләрнең дине булуын күрсәтергә тырышабыз. Яшьләр сәясәтен нәкъ менә шушы фикерне истә тоткан хәлдә гамәлгә ашырабыз да инде.

Аерым алганда, хәзрәт мөселман яшьләренең 1000-нән артык вәкилен берләштергән «MuslimVol» волонтерлар хәрәкәте, елга ике тапкыр уздырыла торган яшьләр форумы эшчәнлекләре, гаилә кыйммәтләрен ныгытуга, яшьләрдә гаилә җаваплылыгын формалаштыру һәм аларның шәхси үсешенә юнәлтелгән «I'MAN» һәм «Яшь килен» проектлары турында сөйләде. Моннан тыш, мөфти яшьләрне тәрбияләү буенча иң нәтиҗәле чараларның берсе буларак, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең спорт проектлары хакында да әйтеп узды. Спорт чаралары яшь мөселманнар мохитендә, шулай ук традицион конфессия вәкилләре арасында берләшүнең, дуслыкны ныгыту һәм үзара аңлашуның мөһим чарасы булып хезмәт итә. ТР мөфтиятенең көрәш, кул көрәше һәм джиу-джитсу буенча турнирлар кебек спорт чаралары яшь мөселманнар арасында аеруча популярлык казанды.

Камил хәзрәт кунакларның игътибарын мөфтиятнең мөһим проектларыннан берсе булган «Ислам. Беренче адымнар» проектына да юнәлтте. Әлеге башлангыч белән яшь мөселманнар халыкны ислам нигезләренә һәм намаз уку күнекмәләренә өйрәтү өчен чыкты. Өч сезон дәвамында әлеге проект курсларында якынча 300-гә якын кеше белем алды һәм намазга басты. Проектның яңа сезоны 100-дән артык кешене колачлады.

Алман кунакларында Россия өчен уникаль булган тагын бер проект – шәригатьнең теге яки бу мәсьәләләре буенча фәтвалар чыгару өчен махсус булдырылган күпка-наллы call-үзәк «Даруль-ифта» аеруча кызыксыну уятты. Мөфти билгеләп узганча, Call-үзәк белгечләре Россия мөселманнарының дингә кагылышлы, шулай ук экстремизмга каршы сорауларына җавап бирә. Моннан тыш, Камил хәзрәт Татарстан мөфтиятенең экстремизмны профилактикалауга юнәлтелгән эшчәнлегенә тукталды. Ул нәзарәт тарафыннан ел саен гамәлгә ашырыла торган «Экстремизмга-юк!» унконлекләре һәм айлыклары кысаларында республикада милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итү буенча зур эш алып барылуы турында сөйләде.

Алга таба мөфтинең мәгълүмати сәясәт буенча киңәшчесе һәм «Хозур» нәшрият йорты директоры Ришат Хәмидуллин ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең агарту инициативалары турында сөйләде. Ул «Хозур» нәшрият йортының 6 ел эчендә Россиядә иң эре Ислам медиахолдингларының берсенә әйләнүен билгеләп үтте. Ришат Әхтәм улы «Хузур ТВ» беренче мөселман телеканалын, 1500-гә якын сирәк һәм борынгы дини китаплар тупланган «Даруль-кутуб» электрон китапханәсен, Россиядә иң популяр ислам порталы дип саналган «Islam-today» сайтын эшләтү буенча тәҗрибә уртаклашты. Моннан тыш, «Хозур» нәшрият йорты директоры Алманиядән килгән кунакларны, соңгы 9 айда аларның ватандашлары «Islam-today» порталына 106 500 тапкыр кергән, дип гаҗәпкә салды. Анары кунакларга мөфтиятнең нәшрият эшчәнлеге – татар классик дини хезмәтләрен, шулай ук секталарның ялган идеяләрен фаш итүгә юнәлдерелгән китаплар, басма матбугат чыгару турында сөйләделәр.

Мөфтинең мәгариф буенча урынбасары һәм РИИ ректоры Рафикъ хәзрәт Мөхәммәтшин үз чиратында делегатларны Татарстанда дини белем бирүнең күпбаскычлы системасы белән таныштырды. Ул билгеләп үткәнчә, республика ислам уку йортлары бөтен Рәсәй һәм БДБ илләре өчен кадрлар әзерли, Рәсәйдә беренче булып белем бирү стандартларын эшләп чыгардылар һәм гамәлгә керттеләр. Ел саен бөтен Россия имамнары өчен квалификация күтәрү курслары үткәрелә. Моннан тыш, мөфтият гамәлдәге имамнарны даими аттестацияләү турында да онытмый.

Очрашу ахырында кунаклар Татарстан мөселманнары башлыгына дистәдән артык сорау белән мөрәҗәгать итте. Аерым алганда, аларны ислам дине тәгълиматларының классик хезмәтләрен мәгариф эшчәнлегендә куллану, Татарстан мөфтиятенең башка ислам илләре белән тәҗрибә уртаклашу, чит ил кешеләре өчен «Дарул-ифта» call-үзәгендә консультацияләр алу мөмкинлеге, Татарстанда хатын-кызның урыны һәм роле, республикада конфессияләр арасында һәм өммәт эчендә тынычлыкка ирешү ысуллары, башка конфессия вәкилләре белән хезмәттәшлек мәсьәләләре кызыксындырды.

Сораулардан тыш, кунаклар Казанда алган тәэсирләре белән уртаклашты, төрле дин һәм милләт вәкилләре арасында дустанә мохит булуын билгеләп үтте. Аларның кайберләре киләчәктә мөфтиятнең яшьләр белән эшләү, төрле конфессия вәкилләре арасында дустанә мөнәсәбәтләр урнаштыру тәҗрибәсен җентекләп өйрәнергә һәм алган белемнәрен үз эшчәнлекләрендә файдаланырга теләк белдерде.

■ dumrt.ru

# Изге гамәл үрнәге

**«Зәкят» фонды үсешләрендә үзенчәлекләре булган балалар, яшүсмерләр, яшьләрне кыска вакытка калдыру үзәге ачты**

Казанда үсешләрендә үзенчәлекләре булган балалар, яшүсмерләр, яшьләрне кыска вакытка калдыру үзәге эшли башлады. Социаль проект ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды тарафыннан тормышка ашырыла. Агымдагы елның августында «Зәкят» хәйрия фонды әлеге чараны булдыру өчен «Татнефть» ГАҖ-нең социаль башлангычлар бәйгесендә җиңү яулады һәм 1 200 000 сум күләмендә грант отты.

«Татарстан Республикасында үсешләрендә үзенчәлекләре булган балалар, яшүсмерләр һәм яшьләрне кыска вакытка калдыру үзәге» проекты үзләренең балаларын – үсешләрендә үзенчәлекләр булган сабыйларны, яшүсмерләрне, яшьләрне калдырып торырга кешеләре булмаган ата-аналарга «хәл алу» өчен шартлар тудыру, балаларны белгечләр кулына кыска вакытка тапшырып тору максатыннан тормышка ашырыла. Үзәк «Зәкят» хәйрия фонды каршында эшли торган «Хәят» социальләшү үзәгенә йөрүче үзенчәлекле балаларның әниләренең күпсанлы үтенечләре буенча тәкъдим ителде. Әлеге ике проект та, беренче чиратта, әни-әниләрне ару-талудан профилактикалауга, балаларны һәм аларның ата-аналарын социаль адаптацияләүгә юнәлдерелгән, чөнки мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләнә торган гаиләләр, барыннан да элек, әйләнә-тирә мохиттән читтә булалар һәм күп вакытларын өйдә һәм тернәкләндерү үзәкләрендә уздыралар.

Татарстан Республикасында үсешләрендә үзенчәлекләре булган балалар, яшүсмерләр, яшьләрне кыска вакытка калдырып тору үзәге ата-аналарга атнага берничә сәгатькә баланы шәфкать туташлары һәм социаль няняларның һөнәри күзәтчелегендә калдырырга мөмкинлек бирә. Баланы билгеле бер вакытка үзәктә калдырып, ата-аналар үзләренең кичектергесез эшләре белән шөгыльләнә алалар, ә бала бу вакытта социаль тернәкләнү уза. Үзәктә булганда балалар сенсор бүлмәсендә педагог-психолог белән дәресләргә, кул хезмәте (рәсем ясау, әвәләп ясау, кул эшләре ясау), музыка, бию терапиясе һәм башка дәресләргә йөриләр. Проектны тормышка ашыру кысаларында үзенчәлекле балалар тәрбияләүче иллетдән артык гаиләне колачлау планлаштырыла. Үзәкнең хезмәтләре – бушлай.

Үсешләрендә үзенчәлекләре булган балалар, яшүсмерләр, яшьләрне кыска вакытка калдырып тору үзәгенә килергә теләүчеләр «Зәкят» хәйрия фонды белгечләренә +7 (843) 225-33-22 телефоны буенча мөрәҗәгать итә ала.

2017 елның декабреннән «Зәкят» хәйрия фонды тарафыннан үсешләрендә үзенчәлекләре булган балалар һәм аларның әти-әниләре өчен «Хәят» үзәге проекты буенча эш алып барыла, ул «Гражданлык җәмгыятен үстерү өчен» РФ Президенты гранты ярдәмендә тормышка ашырыла. Үзәк физик һәм психик сәламәтлекне ныгыту, «үзенчәлекле» балалар һәм аларның әти-әниләрен социальләштерү максатыннан оештырылган. Шунысы игътибарга лаек, Үзәк эшләгәндә бирегә килүчеләрдә үз үсешләрендә уңай динамика күренә. Аларның күбесе аралашырга, бер-берсе турында кайгыртырга, дуслашырга өйрәнә. Үзәктә тулы, тулы булмаган, тәрбиягә бала алган гаиләләр – 3 яшьтән алып 27 яшькә кадәрге мөмкинлекләре чикләнгән балалар катнаша. 2019 елда проект «Хәят» исемен алды һәм үзенә килүчеләр санын 250 кешегә кадәр арттырды. Үсешләрендә үзенчәлек-ләре булган балалар һәм аларның әти-әниләре өчен үзәккә йөрү бушлай.

Моннан тыш, «Ярдәм» милли ислам хәйрия фондының «Берберебезгә ярдәм итик» проекты 2019 елда РФ Президенты грантларының икенче конкурсында җиңүче булды. Проектның максаты – тернәкләндерү курслары аша ДЦП диагнозы булган мөмкинлекләре чикле – коляскадагы инвалидларны, терәк-хәрәкәт аппараты авырулары булган инвалидларны социаль адаптацияләү.

Проект 17 яшьтән һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге, милләтләре, диннәре һәм яшәү урыны буенча чикләнмәгән, инвалид коляскасына утырган һәм ДЦП диагнозлы инвалидларга белем бирү, тернәкләнү узу һәм мәдәни-ял итү характерындагы чаралар комплексын үткәрүне күздә тота.

Әлеге чаралар инвалидларны социаль адаптацияләү максатларында, аларның тормышларындагы тулы яки өлешчә чикләүләрне бетерүгә юнәлдерелгән.

Проект нигезендә махсус эшләнгән укыту программасы ята, ул түбәндәге бүлекләрне үз эченә ала:

- социаль-мәдәни һәм иҗади адаптация курслары программалары;
- физик тернәкләндерү һәм дәвалау физкультурасы курсларын үстерү программалары;
- психоэмоциональ ярдәм курслары программалары;
- мәдәни-ял итү программасы.

Дәресләр шулай итеп төзелгән ки, һәр укучыга мөмкин кадәр уңайлы булсын өчен, аларның эчтәлеге интеллект дәрәҗәсенә, курсларда катнашучыларның физик һәм психологик торышына карап үзгәрә.

Проект кысаларында гомуми саны 100 кешедән торган 5 төркемне укыту күздә тотыла. 20 кешедән торган бер төркем өчен уку вакыты 14 көннән тора. Яшәү, туклану, укыту программасын узу, бәйгедә катнашучылар өчен психологик, медицина һәм юридик ярдәмнәр күрсәтү түләүсез башкарыла, шулай ук, кирәк булганда, аларны озата баручыларның юл чыгымнары күтәрелә.

■ dumrt.ru





# Нух галәйһиссәлам кыйссасы



Нух галәйһиссәлам кешелекнең икенче атасы дип санала. Ул әдәп-әхлакны югалткан халыкка пәйгамбәр итеп җибәрелә. Нух галәйһиссәламнең халкы потларга табына, кешеләргә явызлыклар эшли һәм иң авыр гөнаһларны кыла. Әлеге җәмгыятьнең әдәпсезлегенә карамастан, Нух галәйһиссәлам кечкенәдән хак юлдан бара, бер Аллаһы Тәгаләгә генә гыйбадәт кыла. Ул су сибә, авыл хуҗалыгы эшләре белән шөгыльләнә, кәтүче, балта остасы һәм төзүче була.

Нух галәйһиссәламгә илле яшь тулгач, Аллаһы Тәгалә аңа пәйгамбәрлек бирә һәм ул тугыз йөз илле ел дәвамында пәйгамбәрлек кыла.

Аллаһы Тәгалә бу хакта Коръәндә болай ди:

**«Тәхкыйк Нухны кавеменә пәйгамбәр итеп җибәрдек, ул кавеме эчендә аларны дингә өндәп тугыз йөз илле ел торды, кавеме исә иман китермичә залим булды һәм аларны Туфан суы тотты».**

«Гәнкәбут / Үрмәкүч», 29:14

Асылда, кешелек яшәешенең беренче чорында, потларга табыну булмаган. Ул вакытта бер илаһка гыйбадәт кылу тарала, әмма вакытлар узу белән дингә инану бозыла. Һәм Нух галәйһиссәламнең халкы да туры юлдан читкә тайпыла.

Кайчандыр бу халыктан биш кеше чыккан: Вадд, Сува, Йагус, Йаук һәм Насыр. Алар үзләренең тәкъвалыклары белән билгеле булалар. Риваятьләр буенча, әлеге биш кеше Идрис галәйһиссәлам сәхабәләре булганнар. Аларның бер-бер артлы вафат булулары халыкка зур кайгы китерә. Һәм алар турында истәлекне саклап калу өчен, кардәшләре бу кешеләрнең сыннарын ясый башлый. Кешеләр вакытлар узган саен әлеге сыннар янына йөри башлый һәм хак кешеләрдән ишеткән нәсыйхәтләрне бер-берсенә сөйлиләр.

Әмма берничә буын алышынгач, кешеләр әлеге сыннар ни өчен ясалганлыкны онытa һәм аларны Аллаһыга ширек кыла башлый. Вакытлар узгач, сыннарга табыну әлеге халыкның рәсми диненә әверелә. Ялган дин киң таралыш алгач, Аллаһы Тәгалә кешеләргә Нух галәйһиссәламне җибәрә. Коръәндә моның хакында болай дип әйтелә:

**«Һичшиксез, Без: «Тилмерткеч газап аларга килгәнче, кавемеңне кисәт!» – дип, Нухны кавеменә җибәрдек».**

«Нух», 71:1

## Үзсүзле һәм дингә ышанмаучы халык

Нух галәйһиссәламнең көрәшенә һәм берничә гасырлар дәвамында дингә чакыруына карамастан, аның халкы кяферлектә нык торуын дәвам итә. Бу халык бик тә үзсүзле була. Берничә кешене санамаганда, аларның берсе дә хак юлга басмый. Нух галәйһиссәлам үз халкын ун гасырга якын дингә чакыра, ягъни бу вакыт эчендә кешеләр генә түгел, хәтта ташлар яки агачлар да иман китерә алган булыр иде. Әмма озак вакыт дәгъват алып баруга да карамастан, бу халыкның нибары берничә дистәсе генә иман китерә. Мөфәссирләрнең аңлатма бирүләренә караганда, Нух галәйһиссәлам халкыннан бары сиксән кеше генә динне кабул итә. Кайбер мөфәссирләр исә, Нух галәйһиссәламнең чакыруы белән сигез кеше генә Аллаһыга инанган дип саный.

Пәйгамбәрнең сүзләрен инкяр итү белән генә чикләнмичә, кешеләр Нух галәйһиссәламнең дошманнарына әвереләләр, аның тырышлыкларына һәм дәгъват эше алып баруына каршы киләләр. Бу хакта Коръәндә болай дип әйтелә:

**«Мөхәммәд галәйһиссәламнән элек Нух кавеме, Безнең колыбыз – Нух пәйгамбәрне ялганга тоттылар вә: «Нух мәҗнүн, дивана», – диделәр, кяферләр Нухны артык җәберләүләре сәбәпле, ул аларны дингә өндәүдән тыелды, туктады.**

«Камәр / Ай», 54:9

Башка бер аятьтә әйтелә:

**«Әйттеләр: «И Нух! Әгәр дә ваз кичмәсәң, таш атылганнардан булырсың».**

«Шүгәраү / Шагыйрьләр», 26:116

Әмма Нух галәйһиссәлам аларның янауларына бер дә игътибар итми. Бу басым һәм янаулар аның рухын сындырмый, ихтыяр көчен бетерми, ул кешеләргә Аллаһы Тәгаләдән алынган ачышны җиткерергә омтыла. Ул халыкны дингә чакырып өйдән өйгә йөри. Ишек аша:

– Кем бар? – дип сорыйлар.

Нух галәйһиссәлам:

– Бу – Нух. Аллаһыдан башка бүтән хак илаһ булмаганга һәм мин – Аның илчесе булуына иман китерегез, – дип әйтә.

Бу сүзләрне ишеткәч, күп илаһка ышанучылар Нух галәйһиссәламне мыскыллый торган булалар. Әмма, моңа да карамастан, Нух галәйһиссәлам төшенкелеккә бирелмичә, йорттан йортка йөрүен, халыкны һидаять юлына чакыруын дәвам итә.

Потларга табынучылар Нух галәйһиссәламнең үз дәгъватыннан баш тартмавын күреп, аңа ташлар аталар. Пәйгамбәргә атылган ташлар шулкадәр күп була ки, хәтта зур булмаган калкулык барлыкка килә һәм Нух галәйһиссәлам әлеге ташлар астында кала. Күп илаһка табынучылар «Мөгаен, ул үлгәндер. Ниһаять, без аннан котылдык», дип уйлап, өйләренә таралышалар.

Әмма Аллаһы теләмәсә, кеше кемне дә булса үтерә аламыни? Берникадәр вакыт узганнан соң, Нух галәйһиссәлам аңына килә, ташлар өеменнән чыгып, үзенең дәгъват эшен – тагын йорттан йортка йөрүен дәвам итә. Шулай итеп Нух галәйһиссәлам ару-талуны белмичә күп гасырлар дәвамында кешеләрне иманга һәм дингә чакыра. Кайвакыт күңеле төшеп Аллаһыга ялвара: «И Раббым! Һичшиксез, мин көне-төне кавемемне дәгъват кылдым. Әмма минем дәгъватым аларның ачуларын гына арттырды. Дәгъват иткән саен, алар колакларын капладыр, киемнәренә төренделәр, үҗәтлек күрсәттеләр һәм масаеп, тәкәбберләнделәр», – дип әйтә.

Ләкин Нух галәйһиссәлам, аның халкы иман китермәсә дә, башка буын вәкилләре иман китерәчәгенә ышана. Әмма яңа буын вәкилләре тагын да ныграк монафикълык һәм дингә ышанмаучанлык күрсәтә. Алар хакыйкатьне кабул итмичә, потларга табынуларын дәвам итә. Берничә гасыр дәвамында исламны аңлатуына һәм халыкны иманга чакыруына карамастан, Нух галәйһиссәлам үз халкында иман билгеләрен һәм күңелләре йомшаруны күрмәгәч, Аллаһыга ярдәм сорап дога кыла. Кавем халкы исә: «Әгәр син дөресен сөйлисең икән, безгә илаһыңның нәрсә белән янавы турында әйт», – диләр. Нух: «Теләсә, аны сезгә Аллаһы гына китерә ала. Ул – Раббыгыз. Һәм Аңа гына кайтарылачаксыз», – дип җавап бирә.

Аллаһы Тәгалә бу кавемнең тәкәбберлеге өчен җәзалар җибәреп тора: берничә ел рәттән корылык булып, аларның барлык мал-мөлкәте, терлекләре һәлак була, бакчалары кибә, кисәк кенә туучылар саны кими. Алар мохтаҗлык кичерә һәм ярлылыкта яши башлый. Әмма барыбер иман китермиләр, буйсынмаучанлыкларын тагын да арттыралар. Хәтта Нух галәйһиссәламне үтерү белән куркыталар.

***(дәвамы киләсе санда)***

■ **Камил хәзрәт Сәмигуллин,**
**Татарстан Республикасы мөфтие**

# Изге рабигыль-әүвәл ае мөбарәк булсын!

Изге рабигыль-әүвәл (мәүлид) ае якынлаша. «Мәүлид» сүзе туу дип тәрҗемә ителә. Мәүлид көне – рабигыль-әүвәл аеның уникенче көне. Ул көнне пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм туган. Аның бу дөньяга килүе – Аллаһының олуг бүләге. Рабигыль-әүвәл аенда мөселманнар күркәм мәҗлесләрдә җыелып, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең яшәү рәвеше, әхлагы турындагы аять-хәдисләрне укыйлар, салаватлар әйтәләр, догалар кылалар.

Кайс бине Мәхрам радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Мин һәм Аллаһының Расүле галәйһиссәлам Фил елында тудык» (Әт-Тирмизи). Бу хәдистә әйтелгәнчә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Фил елында туган. Гарәпләрдә тарихи чорларны елның бөек вакыйгалары белән билгеләү гадәте булган, шундыйларның иң мәшһүре – филләр белән бәйле булган вакыйга. Аның кыскача тарихы түбәндәгедән гыйбарәт.

Абиссиния (Эфиопия) Йәмән илен яулап алганнан соң, абиссин патшасы, Йәмәннең хәлифәсе итеп Әбраһә Әл-Әшрамә дигән кешене билгеләгән. Әбраһә барлык абиссиннар кебек насара (христиан) динендә булган. Ул Сәнга шәһәрендә бер зиннәтле чиркәү төзеткән һәм аны Калийс дип атаган, гарәпләрне Кәгъбәтуллага түгел, ә шул чиркәүгә хаҗ кылырга мәҗбүр итәргә тырышкан. Бу эш уңышсыз булганлыктан, Әбраһә үз максатына көч кулланып ирешергә карар кылган. Ул Кәгъбәтулланы җимереп, барлык кешеләрне үз чиркәвенә юнәлдерергә теләгән. Моның өчен зур гаскәр җыйган һәм сугыш өчен кирәк булган барлык әйберләрне әзерләгән. Әбраһә гарәпләрнең күңелләренә курку салыр өчен, күпсанлы филләр белән Мәккә тарафына юнәлгән. Юлда бернинди киртәләр очрамагач, ул Мәккәгә Таиф шәһәре ягыннан якынайган һәм үз гаскәре белән Мугаммис дигән җирдә туктаган. Шуннан соң Әбраһә Мәккәгә юлчабарын җибәргән һәм аңа шәһәрнең аксакалын алып киләргә кушкан. Юлчабар аның сүзен үтәгән һәм Кораеш кабиләсенең аксакалын – Габделмотталибны алып кайткан. Аксакал озын буйлы, зур гәүдәле һәм тәэсирле кыяфәткә ия булган.

Әбраһә аны күргәч, сокланган, үз тәхетеннән торып Габделмотталиб янына килгән. Келәмгә утырып, тәрҗемәчесенә:

– Миннән нәрсә теләгәнен сора, – дигән. Габделмотталиб:

– Синең сугышчыларың минем ике йөз дөямне урлап киттеләр, аларны миңа кайтар, – дигән.

Шунда Әбраһә тәрҗемәчесенә болай дип әйтергә кушкан: «Мин кыяфәтеңне күреп сокланган идем, ләкин сүзләреңне ишеткәч, синә карата фикерем үзгәрде. Мин динегезнең мөбарәк йортын – Кәгъбәтулланы җимерергә килдем, ә син ике йөз дөяңне сорыйсың – дип әйткән. Габделмотталиб: «Мин – дөяләрнең хуҗасы, ә Кәгъбәтулланың үз Хуҗасы бар. Ул аны Үзе саклаячак», – дип җавап биргән.

Аңа дөяләрен кайтарганнар. Мәккәгә әйләнеп кайтканнан соң, Габделмотталиб барлык кешеләргә дә тауларга китәргә әмер биргән, үзе берничә кеше белән Кәгъбәтулла янына килгән һәм аның капкасының бөҗраларын тотып дога кылганнар, Аллаһыдан ярдәм сораганнар.

Әбраһә үзенең гаскәрен һәм филләрен җыеп, Кәгъбәтулланы җимерү нияте белән юлга чыккан. Кинәт нииндидер сәбәп аркасында филләр җиргә ятып, торырга теләмәгәннәр. Кире тарафка бик теләп барганнар, әмма Кәгъбәтуллага борганда атларга теләмәгәннәр.

Көтмәгәндә, Аллаһының ихтыяры белән, төркем-төркем кошлар очып килеп, дошманнарга ташлар ыргыта башлаган. Таш эләккән һәр сугышчы шунда ук һәлак булган. Гаскәр тулысынча тар-мар ителгән, ә Әбраһәнең тәне тарала башлаган. Аны Сәнга шәһәренә алып кайтканнар, ул шунда җан биргән.

Нәкъ менә шул елны Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм анасының карынында була. Әлеге вакыйга Әбраһә гаскәренең җиңелүенә сәбәп була. Бу – Пәйгамбәребезнең бөек шәхес булуына ишарәли.

Әлеге вакыйга турында Аллаһы Тәгалә «Фил» исемле сүрә иңдерә:

**«Әй, Мөхәммәд галәйһиссәлам, күрмәдеңме, синең Раббың фил ияләренә нинди җәза биргәнен? (Мөхәммәд галәйһиссәлам туган елны Йәмән вәлисе Әбраһә, хаҗ кылуны Мәккәдән туктатып үзенең шәһәренә күчерү өчен Кәгъбәтулланы җимереп юк итәм, дип филле гаскәр белән Мәккәгә килде. Ләкин теләгенә ирешә алмады, Аллаһы аларның өсләренә таш яудырып һәлак итте). Әйә Раббың аларның мәкерләрен батыл кылып, тырышуларын бушка чыгарды түгелме? Вә һәлак итмәк өчен алар өстенә төркем-төркем кошлар җибәрде. Кошлар аларны коелган таш белән атарлар. Аларны тапталган, чәйнәлгән салам кеби кылды.»**

«Фил», 105

Дошман тар-мар ителгәннән соң, Аллаһының чиксез рәхмәте һәм рәхсәте белән, бөтен дөньяда изге нур балкыды. Бу нур – сөекле пәйгамберебез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең туусы иде.

Әминә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне тапканда башка хатыннарда була торган берninди авырлыклар сизми, ләкин ул изге төшләр күрә. Аларда: «Дөреслектә, син үзеңдә бу өммәтнең бөек кешесен йөртәсең. Аңа Мөхәммәд дип исем кушарсың», – дип хәбәр бирелә. Шундый төшләрне Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең бабасы Габделмотталиб та күрә.

Аллаһы Тәгалә фил гаскәрен һәлак иткәннән соң илле көн узгач, Әминә бөтен галәмнәргә сөенеч, шатлык, бәхет китерүче изге, нурлы бала таба. Әлеге бөек көн Рабигыль-әүвәл аеның 12 нче көне була. Бу мөбарәк көнне кешеләр күп кенә гадәти булмаган вакыйгаларга шаһит булалар.

1. Сыннар, потлар урыннарыннан кузгала, ә кайберләре сәҗдә кыла, чөнки аларны җимерәчәк кеше дөньяга килә.

2. Мәккәдән чыккан нур Шам (Сүрия) сарайларын нурландыра, чөнки бөтен дөнья буенча иман нурын таратучы кеше туа.

3. Хишам бине Урва сүзләре буенча, бу көнне бер яһүди – Мәккә сәүдәгәре – кораешлар утырган урынга килә һәм: «Әй кораешлылар, бүген сездә бер бала тумадымы?» – дип сорый. Алар: «Белмибез», – дип җавап бирә. Яһүди: «Аллаһу әкбәр! Белмәсәгез, белегез. Мин әйткән сүзләрне истә калдырыгыз. Бүген бу өммәтнең пәйгамбәре дөньяга килде. Аның ике калак сөяге арасында бер билге бар», – ди.

4. Хәссән бине Сабит радыяллаһу ганһе сөйләгән: «Миңа җиде-сигез яшь иде. Мин күргән һәм ишеткән нәрсәләрне аңлый идем. Бер көнне иртә белән Йәсрибтә (хәзерге Мәдинә шәһәре) бер яһүди кешесе кычкырып: «Дөреслектә, бүген Әхмәд (пәйгамбәребезнең икенче исеме) исемле йолдыз балкыды, ул бүген төнлә туачак», – дип әйтте.

5. Мәхзүм бине Хани Әл-Мәхзүми сөйләве буенча, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам туган төнне фарсылар патшасы Хәсрәүнең биләмәләре тетрәнә, унике балконы җимерелә. Утка табынучыларның мең еллар дәвамында өзлексез янган утлары сүнә.

6. Аллаһының Расүле Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәләм туган елда яңгыр күп ява: игеннәр, җиләк-җимешләр башка елларга караганда күпкә уңышлырак була.

Ошбу сүзләр кемгәдер сәер булып тоелырга мөмкин, ләкин бу – хаклык. Бу вакыйгалар төрле тарихчылар тарафыннан өйрәнелгән. Алар барысы да боларның берниндi арттырусыз булганлыгын раслый. Әлеге вакыйгалар Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең киләчәктә бөек шәхес булачагын күрсәтә.

Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең бабасы Габделмотталиб, оныгының тууын белгәч, бик сөенә, тизрәк аны күрергә ашыга. Оныгын кулына алып үбә, аннары аны саклык белән изге Кәгъбәтулла янына алып килә. Габделмотталиб Аллаһыга шөкер итә, оныгы өчен дога кыла, аннары аңа Мөхәммәд дип исем куша.

Мөхтәрәм җәмәгать! Аллаһы Тәгалә безгә иң хәерле, иң гүзәл, вә нурлы пәйгамбәр – Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең өммәтеннән булырга насыйп итте. Раббыбыз Аллаһы бу турыда Коръәни-Кәримдә болай дип әйтә:

**«Ий сез Мөхәммәд галәйһиссәлам өммәте, дөньяга чыгарылган өммәтләрнең иң хәерлесе булдыгыз, Аллаһыга хак ышану илә ышандыгыз, кешеләрне хәерле эшләргә, изге гамәлләргә өнди белү белән өндәдегез һәм бозык, зарарлы эшләрдән тыя белеп тыйдыгыз».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:110

Гомәр бине Хәттаб радыяллаһу ганһе: «Бу аятьтә Аллаһы Тәгалә: «Сез хәерле өммәт булдыгыз», – дип әйтә. Монда сүз сәхабәләр турында бара, чөнки алар чын мәгънәсендә Пәйгамбәребез галәйһиссәллам өйрәткәнчә яшәде, алар аңа ихластан иярде, аннан үрнәк алды. Безгә хәерле өммәт булыр өчен сәхабәләр кебек изге гамәл-гыйбадәтләр кылып яшәргә, һәр урында һәм һәрвакытта да Аллаһыга һәм Аның расүле Мөхәммәд галәйһиссәлламгә итагатьле булырга, үзебезне һәм башкаларны изгелеккә өндәргә һәм явызлыктан тыярга тырышу тиешле», – диде.

Барчабызга да сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәтләрен үтәп яшәргә насыйп булса иде!

■ **Эмир хәзрәт Миңнемуллин,**
**Арча районы мөхтәсибе**

# Кабер эчендә кабер



**Сорау:**

**Кайчандыр берәү күмелгән кабергә билгеле бер вакыт үткәннән соң, икенче кешене күмәргә ярый, дип ишеткәнем бар. Моның хакында динебез нәрсә ди?**

**Җавап:** Фикеһ китапларында, кайчандыр бер кеше күмелгән кабергә күпмедер вакыт үткәннән соң, икенче берәүне җирләргә ярый, дип әйтелгән. Әмма монда, беренче мәетнең гәүдәсе таркалып бетеп, җир белән кушылган булуы шарт («Әл-Фәтва әл-һиндия»).

Кайбер галимнәр, җирләр өчен буш урын булган очракта, кайчандыр кеше күмелгән каберне куллануны мәкруһ хөкемендә, дип әйтә. Әмма мәетне күмәр өчен кабер тапмаган очракта, бу рөхсәт ителгән гамәл булып санала.

Мөхәммәд Әмин бине Габидин: «Бүгенге көндә һәрбер кеше өчен аерым каберлек булдыру кыен булганга күрә, мәетне, аңа кадәр башка берәү күмелгән кабергә урнаштырырга мөмкин. Әмма биредә алдан күмелгән кеше гәүдәсенең таралып, җир белән катнашкан булуы шарт», – дип әйткән.

Ә менә күпме вакыт үткән булуы мәсьәләсенә килгәндә, монда туфракның үзенчәлеге зур роль уйный. Мәсәлән, Сәгуд Гарәбстанында моны өч елдан соң эшләп булса, Истамбулда, алдан кеше күмелгән кабердә икенче берәүне күмә алыр өчен биш ел вакыт үтү кирәк. Ә бездә, билгеле булганча, вакытның тагын да күбрәк узуы таләп ителә.

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

■ **Камил хәзрәт Сәмигуллин, ТР мөфтие**

# Коръәнне хәтем кылу



**Сорау:**

**Дөрес булсын өчен динебез буенча Коръән укуга күпме вакыт сарыф итәргә тиешбез? Изге Китапны елга бер мәртәбә генә уку җитәме?**

**Җавап:** Кайбер галимнәр Коръәнне бер көндә укып чыгуны дөрес гамәл түгел, дип саный. Моның өчен ким дигәндә өч көн сарыф итәргә тиеш, дип саный алар. Һәм әгәр дә кеше елына кимендә бер мәртәбә Коръәни Кәримне хәтем кылса, ул Аллаһы Китабына битарафлык күрсәтүче булып саналмаячак.

«Әл-Фәтава әл-һиндия» китабында болай дип язылган:

«Коръәннең иң яхшы кыйраәте – кешенең укыган вакытта мәгънәләре турында уйлануы».

Коръәнне бер көн эчендә хәтем кылу мәкруһ санала, Аллаһы Китабы өч көннән дә азрак вакыт эчендә укылмый. Галимнәрнең бу мәсьәләдәге иҗмагы «Әл-Кунйә» китабында язылган.

«Әс-Сираҗия» китабында әйтелгәнчә, Коръәнне җәйге вакытта көн башында, ә кышкы вакытта төн башында уку мөстәхәб булып тора.

Кешеләрнең Коръәнне бергәлектә, кычкырып укулары мәкруһ санала, чөнки бу очракта Китапка күрсәтеләсе игътибар юкка чыга. Моның хакында шулай ук «Әл-Кунйә» китабында әйтелә.

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

■ **Камил хәзрәт Сәмигуллин, ТР мөфтие**

# «Әмин» сүзенең әйтелеше

**Сорау:**

**Имам җомга хотбәсен алып барганда кайбер кеше кычкырып «әмин» дип әйтә. Бу рөхсәт ителгән күренешме? Хотбә вакытында сөйләшү тыелган, дип беләидем.**

**Җавап:** Хотбә вакытында имам дога кылганнан соң «әмин» дип әйтү һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең исемен әйткәннән соң салават уку тыелган гамәл (ул мәкруһ тәхрими хөкемендә). Әмма кешенең «әмин» сүзен һәм салаватны эченнән генә укуы рөхсәт ителә.

«Раддел Мөхтәр» китабы 1 нче томының 606 нчы битендә болай дип әйтелгән:

Әл-Бәккали үзенең «Мөхтәсар»ында болай дип яза: «Имам дога кыла башлагач, кешеләрнең кулларын күтәреп «әмин» дип торулары гөнаһ санала, әмма кайбер галимнәр, алар гөнаһлы булмый, тик алай эшләүләре дөрес түгел, дип әйтә. Чынлыкта, фикерләрнең дөресе булып, беренчесе, ягъни гөнаһлы булуы санала, дип әйтелгән. Бу фикергә һәм шулай ук пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең исемен әйткәннән соң салаватны эчтән генә әйтүгә дә фәтва бирелгән».

Шулай ук «Әл-бәхер әр-раик» (2нче том), 156 нчы бит һәм»Әл-Һиндия»нең (1 нче том) 151 нче битендә болай дип язылган:

«Галимнәрнең фикерләрендә салават әйтүгә карата ихтиләф барлыкка килде, әмма дөрес фикер: Пәйгамбәребезгә салаватны һәркем эчтән генә әйтергә тиеш». Нәкъ моның хакында «Фәтхел Кадир» китабында да язылган.

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

■ **Камил хәзрәт Сәмигуллин, ТР мөфтие**



# Мәскәүдә «Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә» басмасы тәкъдим ителде



17 нче октябрь – сафәр аеның 18 нче көнендә, Мәскәүдә Татарстан Республикасының Рәсәй Федерациясендәге Тулы вәкаләтле вәкиллеге мәйданчыгында ТР мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан әзерләнгән «Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә» басмасы – Коръәннең татар теленә тәрҗемәсе тәкъдим ителде. Чарада Татарстан мөселманнары башлыгы, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасының Рәсәй Федерациясендә Тулы вәкаләтле вәкиле Равил Әхмәтшин, мөселман дин әһелләре, дәүләт, җәмәгать, фән эшлекләре, массакүләм мәгълүмат чаралары катнашты.

Фундаменталь хезмәт ТР мөселманнары Диния нәзарәте тарихында Коръән мәгънәләренең үзе әзерләгән беренче тәрҗемәсе булып тора, ул Татарстанда игълан ителгән Коръән тәфсире елы кысаларында дөнья күрде. Басма өстендә эш барышында, мөфтият белгечләре татар һәм иске татар телләрендәге тәфсирләр, аеруча Ногмани, Мөхәммәд Садыйк бине Шаһ Әхмәт Имәнколый Казаниның «Тәсхил әл-бәйан», Шәйхелислам Хәмидинең «Әл-Иткан» хезмәтләре, шулай ук гарәп һәм төрек телләрендәге тәфсирләр, шул исәптән имам Әл-Мәхәлли һәм Әс-Суютыйның «Тәфсир Әл-Җәләләйн» һәм шәех Мәхмүт Әл-Уфыйның «Коръән Мәҗид», Әт-Тәбари, Әл-Матуриди, Ибне Кәсир, Әл-Куртуби, Ән-Нәсәфи, Әлүси хезмәтләрен файдаланды. Моннан тыш, тәрҗемәчеләр, зур игътибар биреп, бүгенге заман татар тәфсирләре авторлары Рабит Батулла, Фәрид хәзрәт Сәлман, Габделбари хәзрәт Исаев һ.б.ның тәҗрибәләренә дә мөрәҗәгать итте.

Коръән мәгънәләренең ТР мөселманнары Диния нәзарәте әзерләгән тәрҗемәсе үзенең төгәллеге белән аерылып тора һәм Каләм Шәрифнең төп нөсхәсенең (оригиналының) синтаксик конструкциясенә һәм лексик составына мөмкин кадәр якын итеп китерелә. Бу исә укучыны мәгънәви ялгышлардан саклый. Укучыларга уңайлы һәм Коръән мәгънәләрен аңлауны җиңеләйтү өчен басманың текстында туры тәрҗемәдән җәяләр белән аерымланган шәрехләр урын алган. Коръәнне шундый рәвештә татар теленә күчерү укучыга аның сүзгә-сүз тәрҗемәсен дә, Изге Китапның тексты иңдерелгән, укылган һәм язылган тарихи-мәдәни шартларын, теленең нечкәлекләрен, төптә яткан мәгънәсен һәм метафораларын да ирештерергә мөмкинлек бирә. Моннан тыш, тәфсирнең һәр битендә Коръәннең тәрҗемә ителгән өлешенең оригинал тексты да урнаштырылган.

ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Коръән мәгънәләре тәрҗемәсе тексты турында уңай бәяләмәләр мөфтиләрдән, башка тәфсир авторларыннан, галим-лингвистлардан, әдәбият, ислам белгечләреннән, Татарстан һәм Россиянең иҗтимагый оешмаларыннан, мөселманнарның Диния нәзарәтләреннән алынды.

Коръән мәгънәләре тәрҗемәсенең икенче басмасы ТР мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан рус телендә әзерләнде.

Татарча һәм русча тәфсирләрне әзерләү башка чаралар белән берләттән, шул исәптә Коръәнне бастыруның Рәсәйдәге традицияләрен торгызу, күпбаскычлы ислам мәгариф системасын һәм ислам мәгариф стандартларын булдыру, мөселман медиакиңлеген барлыкка китерү, хәләл продуктлары һәм хезмәтләренең гомумфедераль бердәм стандартларын эшләү, Татарстан Республикасы Диния нәзарәте тарафыннан Рәсәйдә Исламның алдагы үсеше өчен нигез салу максатыннан башкарылды.

■ **dumrt.ru сайтыннан**

# «Хозур» нәшрият йорты Мәүлид Ән-Нәби якынлашу уңаеннан иҗади бәйге игълан итә

Сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм туган көне – Мәүлид Ән-Нәби бәйрәменә санаулы көннәр калып бара. Шул уңайдан, Татарстан мөфтиятенең «Хозур» нәшрият йорты – теләге булган һәркемне иҗади бәйгедә катнашырга – эссе язарга чакыра.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә карата мәхәббәт камил иман билгесе булып тора. Һәрбер иман әһеле: мин Аллаһы Илчесен чын-чынлап яратаммы? Аның өчен минем калебемдә нинди урын бирелгән? – дигән сораулар хакында уйланырга тиеш. Шуңа күрә бәйгене оештыручылар түбәндәге сорауга игътибар бирергә чакыра: «Сез Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә карата үз мәхәббәтегезне, аңа булган сөю хисегезне ничек белдерер идегез?»

Эссе форматында язылган уй-фикерләр татар һәм рус телләрендә кабул ителә. Бәйгедә теләгән һәр кеше катнаша ала (18 яшьтән өлкәнрәк булу һәм Россиядә яшәү шарт).

Җиңүчеләр дипломнар һәм акчалата премияләр белән бүләкләнәчәк:

– беренче урын өчен – 10 мең сум;

– икенче урын өчен – 5 мең сум;

– өченче урын өчен – 3 мең сум.

Бәйгенең Нигезләмәсе белән Диния нәзарәте сайтында танышырга мөмкин. Гариза җибәрү өчен сылтама да шунда ук күрсәтелгән.

Иҗади эшләрне islam_today@mail.ru электрон почтасына кабул итү вакыты: 14.10.2019 – 06.11.2019.

Бәйге нәтиҗәләре 2019 елның 9 ноябрендә ВКонтакте битендә игълан ителәчәк.

# Төркиянең Казандагы яңа генераль консулы Татарстан мөфтиятендә булды



15 нче октябрь – сафәр аеның 16-нчы көнендә, нәзарәттә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Төркиянең Казандагы яңа Генераль консулы Исмәт Эрикан белән очрашты. Мөхтәрәм кунакны ихлас сәламләп һәм яңа керешкән вазифасында уңышлар теләп, мөфти хәзрәт Исмәт бәйне бик теләп Татарстан мөселман өммәте тормыш-яшәеше, нәзарәтнең төп эш юнәлешләре, республикабыздагы дини вәзгыять, татар дин галимнәренең мирасы белән таныштырды. Очрашу барышында үзара хезмәттәшлек итү мәсьәләләренә кагылышлы фикерләр әйтелде.

Иң беренче чиратта мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Төркиянең Казандагы баш илчесен Татарстанның дин әһелләре, имам-мөхтәсибләр, казыйлар, күренекле җәмәгать эшлеклеләре, шәкертләр катнашында Шәһре Болгарда узачак Мәүлид Ән-Нәби бәйрәменә чакырды: «Һәр елдагыча Болгар шәһәрендә Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Мәүлиден үткәрергә дин кардәшләр белән бергәләп җыелырга ниятлибез. Быел да әлеге мөбарәк чара 8 нче ноябрь көнне ахшам намазыннан соң узар дип көтелә. Соңгы ике елда Мәүлид кичәсен быел беренче ислам докторларын укытып чыгарган Болгар ислам академиясе бинасында үткәрдек. Быел да, әлеге матур традицияне дәвам итеп, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре, имам-мөхтәсибләр, дин белгечләре, шәкертләр катнашында Мәүлид касыйдәләре, вәгазьләр укырга, мөнәҗәтләр әйтергә ниятлибез. Сезне мөбарәк бәйрәмебездә күрергә бик шат булыр идек, рәхим итегез!» Яңа илче әлеге чакыруны кабул итеп алды.

Алга таба сүз барышында Камил хәзрәт бик теләп нәзарәтнең проектлары белән таныштырып узды. Сүз, аерым алганда, «Хозур ТВ» мөселман телеканалы эшчәнлеге, татар дин галимнәренең мирасын торгызу һәм халыкка җиткерү хакында иде. Моннан тыш, Татарстан мөфтие Төркиянең Казандагы Баш консулын быелның Рамазан аеның беренче көненнән нәзарәттә ачылган «Даруль-ифта» call-үзәге һәм аның эшчәнлегенең кайбер нәтиҗәләре белән таныштырды: «Даруль-ифта» – шәригатьнең теге яки бу мәсьәләләре буенча фәтвалар чыгару өчен махсус булдырылган күпканаллы call-үзәк. Теләге булган һәркемнең эш көннәрендә сәгать 10.00нан 16.00га кадәр 8 800 222 7667 номерына шалтыратып, үзен борчыган сорауларга бик теләп җавап алырга мөмкинлеге бар. Күпканаллы линиягә мөрәҗәгать итүчеләр белән шәригать белгечләре аралаша. Шунысы күркәм, безнең белгечләр шалтыратучылар белән җиде телдә аралаша. Республикабызда рәсми саналган татар һәм рус телләреннән кала, гарәп, таҗик, шул исәптән төрек, фарсы, инглиз, француз телендә аңлаша алалар», – дип аңлатма бирде Камил хәзрәт.

Төркиянең Казандагы яңа Генераль консулы Исмәт Эрикан шулай ук хәләл индустриясен үстерү өлкәсендә хезмәттәшлек буенча тәкъдимнәр белән чыкты.

Очрашу ахырында киләчәктә үзара хезмәттәшлек алып бару юнәлешләре һәм мөмкинлекләре буенча узган очрашу истәлеге итеп Камил хәзрәт Баш консулга «Хозур» нәшрияты бастырган китапларны тапшырды. Мөхтәрәм кунакта аеручa «Хозур» нәшрият йорты чыгарган XX йөз башында нәшер ителгән «Русча-татарча мөкәммәл лөгат» сүзлегенең репринт басмасы зур кызыксыну уятты.

■ **dumrt.ru сайтыннан**

# Мәүлидүн-нәби бәйрәме хакында

Элеккеге заманнарда пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәтләренең туган көнен аерым-ачык билгеләп бәйрәм итү һәм шул көндә фәкыйрь-мескеннәрне ашлар ашатып, аларны садакалар биреп шатландыру, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тууы, үсүе хакында гарәп яки төрки телләрдә бәян ителгән касыйдәләрне укылганы төгәл билгеле түгел.

Әмма һиҗри исәп белән алтынчы гасырда, Ирбиль падишаһы, Мәлик Мозаффар Әбү Сәгыйт Күкбүре бине Гали бине Биктәгин (Әрбил хөкемдары (1190–1232). Ул беренчеләрдән булып 1207 елны Мәүлидне бәйрәм буларак оештырган кеше), Мөхәммәд Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмне ихлас күңеленнән яратканга һәм үзе дә бик юмарт кеше булганга күрә, шушы «Мәүлид – шәриф касыйдәсе»н укуны һәм зур табыннар – ашлар әзерләп, халыкны җыеп ашатуны, шунда күп изгелек кылып, садакалар таратып, кешеләргә ярдәм итүләрне гадәткә кертә. Ул һәр ел саен «Мәүлид – шәриф» көнендә галимнәрне, мәшәехләрне һәм дә күп санлы фәкыйрьләрне җыеп зур аш мәҗлесе ясый. «Мәүлед – шәриф» касыйдәләрен укучыларга һәм голямә, мәшәехләргә яхшы, матур киемнәр бүләк итеп, якынча, өч йөз мең алтын микъдарында мал сарыф итә. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмне бик тә яратканга күрә, күңеле тулып, аның өммәтен, бихисап фәкыйрьләрне һәм гыйлем әһелләрен, бу «Мәүлид – шәриф» бәйрәме хөрмәтенә, күп маллар сарыф итеп, шатландыра торган була.

## Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам – иң камил кеше

Мөхәммәд галәйһиссәлам, пәйгамбәрләр имамы буларак, барлык пәйгамбәрләрнең иң матур сыйфатларын үзендә туплаган. Ул мул сулы елгалар койган диңгез кебек. Һәрбер кеше аның тормышын үзенә үрнәк итеп алырга мөмкин. Мөхәммәд галәйһиссәлам үзенең бер хәдисендә: «Мин күркәм әхлакны камилләштерү өчен җибәрелдем», – дип әйткән.

Аллаһы Раббыбыз да Коръәни Кәримендә пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләмне мактап:

**«Хакыйкатьтә, син – югары әхлак иясе»,** – дип әйткән.

«Нун», 68:4

Ул игелекле, итагатьле, шәфкатьле, миһербанлы, сабыр, киң күңелле, юмарт, ышанычлы, тыйнак иде. Бу сыйфатлар Пәйгамбәребез галәйһиссәламдә иң камил дәрәҗәдә була.

Аллаһының Расүле гәләйһиссәлам: «Миңа тәрбияне Аллаһы Үзе бирде, һәм бу тәрбия нинди күркәм булды», – дигән.

Сәхабәләр Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең күркәм яшәү рәвешен, әдәбен күреп бик сокланганнар. Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһе болай дигән: «Мин Аллаһының Расүле гәләйһиссәламгә ун ел хезмәт кылдым. Бер мәртәбә дә ямьсез сүз сөйләгәнен ишетмәдем. Беркайчан да: «Бу эшне ник болай эшләдең?» – дип ачуланганын күрмәдем», – дигән.

Аллаһы Расүле галәйһиссәлам күршеләрен хөрмәт иткән һәм кунакларын ихтирам белән кабул иткән. Аның Аллаһы өчен хезмәт итмәгән яки яхшы гамәл кылмаган бер генә минуты да булмаган. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам киләчәккә өмет белән караган, төшенкелеккә бирелүне яратмаган. Ул ике эшнең берсен башларга кирәк булганда, аларның иң файдалысын сайлаган, бәлагә төшкәннәргә ярдәм итәргә һәм мәзлүмнәрне коткарырга яраткан.

Аллаһы Илчесе галәйһиссәлам үзенең сәхабәләрен бик яраткан, алар белән еш киңәшләшкән һәм алар турында кайгырткан. Әгәр сәхабәләреннән берәрсе авырып китсә, ул аларның хәлен белергә бара торган булган. Әгәр берәрсе югалып торса, аны эзләгән. Берәрсе вафат булса, аның хакына дога кылган. Ул һәрвакыт башкаларның гафу үтенүен кабул иткән, аның өчен көчле дә, көчсез дә үз хокукларында тигез булган. Сүз остасы буларак, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам күп төрле гыйбрәтле хикәяләр һәм тарихлар сөйли торган булган.

Аллаһы Расүле галәйһиссәламнең тәрбиялелеге һәм әдәплелегенә килгәндә, ул сәхабәләренә бик мәрхәмәтле, хөрмәтле мөнәсәбәттә булган, кысан җирдә һәрвакыт башкаларга күбрәк урын калдырган. Берәрсен күрсә, ул аны һәрвакыт беренче булып сәламләгән.

Аллаһы Илчесе галәйһиссәлам бик тыйнак булган. Кешеләр җыелган җиргә яки җыелышка килгәч, урын бар җиргә утырган һәм моның белән барысының да бертигез хокуклы икәнлеген ассызыклаган. Әңгәмәдәше белән утырганда, беркайчан да аннан алда торып басмаган. Ашыккан вакытта һәрвакыт гафу үтенгән.

Пәйгамбәребез галәйһиссәләм беркайчан да ярлыларга фәкыйрьлекләре өчен җирәнеп карамаган, байлар алдында түбәнчелек күрсәтмәгән. Ул һәрвакыт иминлекне югары куйган. Ашаганда, эчкәндә уң кулын файдаланган, чөнки аңа Аллаһы шулай кушкан. Ул хуш исләрне яраткан: суган, сарымсак кебек авыр ис таратучы нәрсәләрне сөймәгән. Аллаһы Илчесе галәйһиссәлам үзенең сәхабәләреннән киеме белән дә, җыелышларда утырган урыны белән дә аерылып тормаган. Пәйгамбәребезне белмәгән берәр кеше килсә: «Ә сезнең кайсыгыз Мөхәммәд соң?» – дип сорый торган булган.



## Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламгә карата булган әдәп

Сәхабәләр сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәламгә карата һәрвакыт әдәпле булганнар. Алар: «Без Аллаһының Расүле галәйһиссәламнең нәсыйхәтләрентыңлаганда, күңелләребез Раббыбыз Аллаһыга һәм Аның пәйгамбәре Мөхәммәд галәйһиссәламгә карата мәхәббәт һәм әдәп белән тула иде, әйтерсең лә башларыбызга кошлар кунган һәм әгәр без хәрәкәтләнсәк, ул кошлар очып китәр иде», – дип әйтә торган булган.

Сәхабәләр Пәйгамбәребез галәйһиссәламгә сорау бирергә һәм аның күзләренә туры карарга да оялганнар. Хәтта Аллаһының расүле Мөхәммәд галәйһиссәлам янәшәсендә еш булган сәхабәләр дә, аңа карата әдәп саклап, аның күзләренә ачык карый алмаганнар. Имам Тирмизи рахимәһуллаһи хәбәр иткәнчә, бары тик Әбү Бәкер белән Гомәр радыяллаһу ганһүмә генә аның күзләренә карап сөйләшә алганнар, калган сәхабәләр Пәйгамбәребез галәйһиссәлам белән сөйләшкәндә күзләрен читкә ала иделәр.

Коръәндә пәйгамбәрләрнең исемнәре китерелгән булса да, Аллаһы Тәгалә соңгы Пәйгамбәргә бер тапкыр да «Йә Мөхәммәд» дип мөрәҗәгать итмәде. Аллаһы Раббыбыз аңа «Йә Нәби», «Йә Расүл», дип эндәште. Аллаһы Тәгалә барлык мөселманнарга Пәйгам-бәребез галәйһиссәламгә карата әдәпле булырга боерды.

## Мәүлид кичәсенең фәзыйләтләре

Хәзрәти Мәгъруф Әл-Кәрхый (Аллаһы аны үз рәхмәтеннән аермасын) болай дигән: «Кем дә булса салләллаһу галәйһи вә сәлләм мәүлиден укытырга ризык хәзерләсә һәм мәүлидне хөрмәтләп, туган, дусишләрен җыйса, өен ут белән яктыртса, яңа киемен киеп, хуш исләр, хуш исле-майлар белән сөртенсә, Аллаһы Тәгалә Кыямәт көнендә ул бәндәне Пәйгамбәрләр белән бер төркемдә булдырыр һәм (аның урыны) югары Гыйллийиндә (җиденче күктә) булыр», – дигән.

Заманының бердәнбере, гасырында берүзе (сыйфатларына карата) булучы Имам Фәхретдин Әр-Рази болай әйткән: «Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм мәүлиден тоз, яисә бодай, яки башка бер ризык өстенә укыса шул ризыкка бәрәкәт иңәр. Инде су өстенә мәүлид укылганнан соң, ул суны эчүченең калебенә (йөрәгенә) мең нур һәм шәфкать хисләре керер, мең явызлык һәм авыру чыгып китәр. Мондый йөрәк, башка йөрәкләр үләчәк көнне үлмәячәктер». Сүз Кыямәт көне турында бара.

Галимнәрнең солтаны Имам Җәләледдин Әс-Суютый (Аллаһы аны үз рәхмәтеннән аермасын) болай дип әйткән: «Берәр йортта, яисә мәчеттә, яисә берәр мәхәлләдә (кварталда) Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм мәүлиде укылса ул йортның, яисә мәчетнең, яки мәхәлләнең тирәякларын фәрештәләр чорнап алалар һәм шушы урынның халкына фәрештәләр салават әйтеп торырлар һәм барысына да Аллаһы Тәгалә тарафыннан мәрхәмәт һәм Аллаһының разыйлыгы насыйп булыр. Җәбраил, Микаил, Исрафил һәм Газраил галәйһимуссәлам фәрештәләр исә мәүлид укуга сәбәпче кешегә үзләре салават әйтерләр». Һәм аның хәбәр итүенчә: «Әгәр берәр мөселманның өендә мәүлид укылса, ул өйгә Аллаһы Тәгалә рәхмәте белән корылык тимәс, вәба (чума) авыруы кермәс, ут тимәс, су (ташкын) тимәс, бәла-афәтләр, нәфрәт, хөсет, явыз күз, караклардан имин булыр. Әгәр мәүлид укучы бәндә вафат булса, Аллаһы Тәгалә Мөнкир вә Нәкир сорауларына җавап бирүне җиңеләйтер, һәм ул бәндә кодрәтле Аллаһы Тәгаләнең хаклык урынында булыр».

■ **«Мәүлид Ән-Нәби» китабыннан**

# Әбү Габдулла Мөхәммәд бине Сәламә бине Җәгъфәр Әл-Кудагый

Данлыклы мөхәддис (хәдис галиме), казый, тарихчы, дипломат Әбү Габдулла Мөхәммәд бине Сәламә бине Җәгъфар Әл-Кудагый һиҗри 380, милади 990 еллар тирәсендә Каһирәдә (Мисыр) туып, һиҗри 454, милади 1062 елда вафат була. Тумышы белән бәни Кудага кабиләсенә бәйле булганга, Кудагый дигән исем белән танылган. Үз заманында Багдад, Мосул, Димәшкъ, Искәндәрия, Хорасан, Шираз кебек шәһәр һәм өлкәләрдән килгән олы, мәшһүр галимнәр белән күрешә. Алар арасыннан: кыйраәт галиме Әбү Габдулла Әхмәт бине Әл-Җизи, мөхәддисләрдән Әбү Мөслим Мөхәммәд бине Әхмәт бине Гали, Әбү Хәсән Әхмәт бине Габделгазиз бине Сарсал һәм Әбү Мөхәммәд Габдрахман бине Гомәр Әл-Туҗиби, танылган Факыйһ Ибне Нәххас, мотасавиф (тәсаввуф галиме) Әбү Хәсән Гали бине Габдулла бине Җәһдам Әл-Хәмадани һ.б. кебек танылган галимнәрдән гыйлем өйрәнә. Мәккә, Истамбул, Рамлә һәм Тараблүс әш-шамга барып, 130га якын галимнәрдән хәдис риваять итү рөхсәте (иҗәза) ала. Фикеһ буенча шафигый мәзһәбендә, ягъни гамәлдә әһле Сөннәт Вәл-Җәмәгать галимнәре юлын тота. Игътикадта әшгарый мәзһәбендә. Аның үзеннән Хатип Әл-Багдади, Әбү Фәраҗ Сәһле бине Бишер Әл-Исфрайини, Ибне Макулә, Мөхәммәд бине Футух Әл-Хәмиди, Әбү Сәгыйд Габделҗәлил Әс-Сәви, Әбү Габдулла Мөхәммәд бине Әхмәт Әр-Рази һәм хәзрәти Галинең оныкларыннан, «Нәсиб» исеме белән искә алынган Әбү Әл-Касыйм Гали бине Ибраһим Әл-Галәви Әл-Хөсәйни кебек галимнәр хәдисләрне риваять иткәннәр.

### Әбү Габдулла Мөхәммәд бине Сәламә бине Җәгъфар Әл-Кудагыйның вазифалары

Кудагыйның иң күп хезмәт кылган чагы Фатимиләр хәлифәсе Мөстансыйр Билләһ заманына туры килә. Казый буларак киң катламга танылуы белән берлектә, Фатимиләр чорында вәзир сәркатиплеге, илчелек һәм казыйлык вазифаларында хезмәт кыла (Кинди 63 б.). Мөстансыйр Билләһ һиҗри 447, милади 1055 елда аны Константинопольга (Истамбул) илче итеп җибәрә. Шунда шул ук вакытта сәлҗек солтаны Тугърул бәйнең илчесе белән бер арага килә. Солтан Тугърул бәйнең Бизанс (Византия) императрицасына җибәргән хатындагы соравы буенча, сәлҗек илчесенә Константинополь (Истамбул) мәчетендә җомга намазының хотбәсендә Габбасиләр хәлифәсе Каим Биәмриллаһ исемен кушып укырга рөхсәт ителә. Тарихтан билгеле булганча, бу ике Габбасиләр белән Фатимиләр хәлифәлекләре арасында каршылыклык, дошманлык сөргән чорга туры килә. Бу вакыйга турында Кудагый, илче буларак, үзенең җитәкчесе Фатимиләр хәлифәсе Мөстансыйрга хәбәр җиткерә. Бу хәбәрне ишеткәч, Мөстансыйр Билләһ Бәйтелмокдистәге (Иерусалим) Камәмә чиркәвендәге христианнар өчен кодси, изге булган әйберләрен үз кулына ала. Шул вакыйгадан соң Бизанс гаскәрләре Фатимиләрнең диңгез буендагы җирләрен яулап алып, Каһирә шәһәрен камап алалар. Һиҗри 454, милади 1062 елга кадәр дәвам иткән кытлык сәбәбендә, Мисырда ваба хастасы кизүе башлана (Макризи 1 т. 335 б.). Бик күп халык ачлык һәм ваба кизүеннән үлә. Шулар арасында олы шәхес буларак өлгереп җитешкән Әбү Габдулла Мөхәммәд бине Сәламә бине Җәгъфар Әл-Кудагый хәзрәтләре дә һиҗри 454, милади 1062 елның декабрь аеның 21 көнендә вафат була. Кабере Карафәдәге Нәҗҗар зияратында.

### Әбү Габдулла Мөхәммәд бине Сәламә бине Җәгъфар Әл-Кудагыйның әсәрләре


«Шиһаб әл-әхбәр». Баш хәрефләре бер булган, кыска хәдисләрдән тупланган бу җыентык «Әш-Шиһаб фил хикәм вәл-әдәп» исеме белән танылып, киң таралыш тапкан.

«Мөснәд әш-шиһаб». «Шиһаб әл-әхбәр»дәге хәдисләрнең иснәдләре белән бергә җыелган әсәре.

«Дөстүре мәгалим әл-хикәм вә мәгъшүре мәкарим әш-шиям». Хәзрәти Галинең үгет-нәсыйхәтләре, әдәби сүзләре, сорауларга җаваплары, догалары, аеруча шигырь һәм тәмсилләреннән тупланган әсәр.

«Әл-мохтар фи зикр әл-хитат вәл-әсәр». Бу әсәрдә Мисырның топографиясе булдырылган.

«Әл-инбәгъ би әнбәгъ әл-әнбия вә тәварих әл-хөләфә вә виләят әл-өмәра» («Әл-Инбәгъ ганил әнбия», «Әнбәгъ әл-әнбия», «Тарих Әл-Кудагый», «Гуюн әл-мәгариф вә фөнүне әхбәр әл-хәләиф»). Пәйгамбәрләр, хәлифәләр һәм бәйлекләр тарихы буларак өч бүлемнән торган әсәр дөнья яратылганнан алып, һиҗри 427, милади 1036 елга кадәр булган вакытны үз эченә алып, Габбасиләр һәм Фатимиләр чорын күрсәткән бер мохтасар (кыскартылган) тарих китабы булып санала.




«Дакаикуль әхбәр вә хәдаикуль игътибар». Вәгазь, нәсыйхәт һәм зикер китабы булган әсәр төрки телләргә тәрҗемә ителеп, киң таралыш тапкан. Бу әсәр ун гасыр буенча бүгенге көнгә кадәр безнең төрки халыкларда иң популяр китаплардан санала.

Моннан тыш, «Тәфсир Әл-Коръән» (20 том), «Мәнакыйб әш-Шәфигый», «Мөгъҗәм әш-шуюх», «Әмәли фил хәдис», «Әл-Инбәһ фил хәдис», «Әл-Әгъдәд» (Әл-Гадәд) әсәрләре булганы билгеле.

# «Габәдилә»

«Габәдилә» дип Габдулла исемле дүрт сәхабәгә карата әйтәләр. Алар үзләренең гыйлемнәре һәм фәтва чыгара алулары белән танылу алганнар.

### Габдулла бине Мәсгуд

Габдулла бине Мәсгуд беренче мөселманнардан була. Ул мәҗүсиләрнең кысрыклавына карамастан, Коръәнне Кәгъбәдә укыган беренче сәхабәләрдән. Шулай ук Коръәнне матур укуы белән дә танылган.

### Габдулла бине Гомәр

Габдулла бине Гомәр – Гомәр радыйаллаһу ганһенең улы. Үзенең апасы Хафса аркасында ул һәрвакыт Мөхәммәд галәйһиссәләм янәшәсендә була һәм аннан бик күп гыйлем ала.

### Габдулла бине Габбас

Габдулла бине Габбас – Мөхәммәд галәйһиссәләмнең абзыйсы Габбасның улы. Ул Пәйгамбәребезнең түбәндәге догасына ия була: «Йә Раббым, аңа Коръән өйрәт һәм аны дин өлкәсендә белгеч яса!» (Бохари, Гыйлем, 17)

### Габдулла бине Зөбәер

Габдулла бине Зөбәер – Әбү Бәкернең кызы Әсма радыйаллаһу ганһәнең һәм Зөбәер бине Гәввамның улы. Ул фәнни эшчәнлектән тыш, дәүләт белән дә идарә иткән.

Габдулла бине Гамер бине Гас әтисенә караганда беренчерәк ислам динен кабул итә. Пәйгамбәребез галәйһиссәламнән бик күп белем ала. «Габәдиләр» атамасына лаек булган дүртенче сәхабәнең: Габдулла бине Мәсгуд яки Габдулла бине Гамер бине Гас булуы әлегә кадәр бәхәсле сорау булып тора.

# Кәгъбәтуллаһ ачкычын саклаучы Госман бине Талхә тарихы



Бүгенге көнгә кадәр Кәгъбәтуллаһ ачкычы Госман бине Талхә радыяллаһу ганһе нәселеннән булган кешеләрдә саклана.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәккәгә кайтканнан соң, Кәгъбәтуллаһ ишекләре ябык икәнен күрә. Ачкыч Госман бине Талхәдә була. Әлеге кеше бу вакытта мөселман булмый һәм шуңа да Аллаһы йортын бикләп куеп качкан була. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәккәгә керү белән күп кеше Исламга килә. Аллаһы Илчесе ачкычның кемдәлеген сорый, аңа Госман бине Талхәне күрсәтәләр. Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһе Госман бине Талхәгә килеп: «Йә, Госман! Ачкычны бир. Аны Аллаһы Илчесе эзли», – ди. Госман бине Талхә: «Йә, Мөхәммәд! Әгәр мин синең «пәйгамбәрлегеңә ышансам, күптәннән синең өчен Кәгъбәтуллаһны ачар идем», – ди. Госман бине Талхә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең пәйгамбәрлегенә ышанмыйча, ачкычны бирүдән баш тарта. Гали радыяллаһу ганһе ачкычны урлап, Кәгъбәтуллаһны ача. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аллаһы йортына кереп, анда ике рәкәгать намаз укый. Расүлебезнең абыйсы Габбас бине Габделмотталиб аңа: «Син безнең нәселебез хаҗиларны су белән тәэмин итү өчен җаваплы булганын беләсең. Шуңа күрә әгәр дә ачкычны безнең кулга бирсәң, безгә икеләтә хөрмәт күрсәткән буласың: без хаҗиларга су да эчерә алачакбыз һәм кирәк булганда синең өчен Кәгъбәтуллаһның ишекләрен дә ачарбыз», – ди. Бу вакытта Кәгъбәтуллаһка аять белән Җәбраил фәрештә иңә: **«Дөреслектә, Аллаһы әманәтләрен әһелләренә тапшырырга сезгә әмер итәдер һәм кешеләр арасында хөкем итсәгез, гаделлек белән хөкем итегез, диядер. Аллаһының сезне Коръән белән вәгазь кылуы ни хуш нигъмәттер. Әлбәттә, Аллаһы сүзләрегезне Ишетүче, эшләрегезне Күрүче булды».**

«Нисә / Хатыннар», 4:58

Бу аятьтән соң Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм ачкычны Госман бине Талхәгә кайтарырга кирәк икәнен аңлый. Шул ук вакытта Гали радыяллаһу ганһене чакырып алып аңа ачкычны Госман бине Талхәгә тапшырырга һәм урлаганы өчен гафу үтенергә куша. Гали радыяллаһу ганһе Госман бине Талхә янына килеп: «Йә, Госман, менә синең ачкычың. Аны урлап алганым өчен мине гафу ит», – диде.Госман бине Талхә гаҗәпләнеп, йә Гали, берничә минут элек кенә син мине әрләп, миңа янап чыгып киткән идең, хәзер килеп тыйнак рәвештә гафу үтенәсең, нәрсә үзгәрде соң, дип сораган. Гали радыяллаһу ганһе: «Аллаһы белән ант итәм, Госман. Әле генә Аллаһы Пәйгамбәребезгә сиңа кагылышлы аять иңдерде һәм сакларга дип тапшырылган әманәтне кире кайтарырга кушты. Бары шул сәбәп белән генә мин сиңа ачкычны кайтарып бирәм», – дигән. Госман бине Талхә бу сүзләргә тәэссирләнеп, ләә иләәһә илләллаһу Мухәммәдүррасүлүллаһ кәлимәсен китерде һәм мөселман булды. Бу хәлләргә җавап итеп Җәбраил фәрештә икенче тапкыр, монысында инде Пәйгамбәребезгә әмер белән килә: «Йә, Мөхәммәд! Госман бине Талхә янына барып хәбәр ит: ачкыч Кыямәт көненә хәтле аның гаиләсендә булачак», – ди. Шушы көнгә хәтле Кәгъбәтуллаһның ачкычы Госман бине Талхәгә нәселеннән булган кешеләрдә саклана. Шул рәвешле вәхи иңүнең көче күрсәтелә. Күз алдыбызга гына китерик, Пәйгамбәребезнең абыйсы үзенә хөрмәт күрсәтүне сорап, аннан ачкычны үзенә бирергә тәкъдим итә һәм аны бары хәерле гамәлләрдә генә кулланачагына сүз бирә. Әмма, Госман бине Талхә мәҗүси булуына карамастан, Аллаһы Тәгалә ачкычны аңа кайтарырга әмер бирә. Бу вакыйгадан, Раббыбызның ихтыяры һәм гаделлеге безнең мәнфәгатьләрдән өстенрәк икәнен аңлыйбыз. Аллаһы Үзенең хикмәте белән ачкыч мәсьәләсен шулай хәл итте һәм пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аңа буйсынды. Гәрчә аңа хәтле абыйсы ачкычны үзенә кайтаруын сораган иде һәм башка очракта Расүлебез аңа каршы килә алмаган булыр иде. Бу Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Ислам мәнфәгатьләрен үзенекеннән һәм башка элемтәләрдән югарырак куйганын күрсәтә.

■ **Islam-today сайтыннан**

# Үлем мизгелендә укыла торган дога

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам мәңгелеккә китәр алдыннан үлем түшәгендә ятканда болай дигән:

اللَّهُمَّ أَعِنِّي غَمَرَاتِ الْمَوْتِ وَسَكَرَاتِ الْمَوْتِ.

«Аллааһуммә әгыйннии гамәраатил-мәүти вә сәкәраатил-мәүүт».

«Аллаһым! Үлемнең авырлыгыннан һәм үлгәндә үз-үзеңне белештермәүгә каршы миңа ярдәм ит».

Аннан соң Пәйгамбәр галәйһиссәлам үлгәнче бу доганы укыды:

اللَّهُمَّ اغْفِرْلِي وَارْحَمْنِي وَأَلْحِقْنِي بِالرَّفِيقِ الْأَعْلَى.

«Аллааһуммә-гъфир лии вәрхәмнии вә әлхикъни биррафиикыйл-әгьләә».

«Аллаһым! Мине гафу ит, миңа мәрхәмәтең белән кара һәм мине иң якын дуска (Сиңа) алып бар» (Бохари: 1668).

# Кабер газабыннан котылу өчен укыла торган дога

Бу Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең өйрәткән догаларыннан берсе:

اللَّهُمَّ إِنِّي أَعُوذُ بِكَ مِنْ عَذَابٍ فِي النَّارِ وَعَذَابٍ فِي الْقَبْرِ.

«Аллааһуммә инннии әгүүҙү бикә мин гәҙәәбин фин-нәәри үә гәҙәәбин фил-кабр».

«Аллаһым! Ут эчендә һәм кабердә газапка дучар булудан сиңа сыенам».

# Нерв авыруына каршы дога

وَبِقُدْرَةِ بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ ارْفَعْ قَدْرِي وَاشْرَحْ صَدْرِي وَيَسِّرْ أَمْرِي وَارْزُقْنِي مِنْ حَيْثُ لَا أَحْتَسِبُ بِفَضْلِكَ وَكَرَمِكَ وإِحْسَانِكَ يَا مِنْ هُوَ كٓهيٰعٓصٓ حٰمٓ عٓسٓقٓ وَأَسْأَلُكَ بِجَمَالِ الْعِزَّةِ وَجَلَالِ هَيْبَتِكَ وَعِزَّةِ الْقُدْرَةِ وَجَبَرُوتِ الْعَظَمَةِ أَنْ تَجْعَلَنِي مِنْ عِبَادِكَ الصَّالِحِينَ الَّذِينَ لَا خَوْفٌ عَلَيْهِمْ وَلَا هُمْ يَحْزَنُونَ

«Вә бикудрати бисмилләәһиррахмәәнир-рахиим ирфаг кадърии вә-шрах садрии вә йәссир әмрии вәр-зукъни мин хәйсү ләә әхтәсибү би фадликә вә кәрамикә вә ихсәәникә йәә мән һүә кәәф һәә йәә гайн саад хәә миим гайн сиин кааф вә әс-әлүкә би җәмәхәлилгыйззәти вә җәләәли һәйбәтикә вә гыйззәтил-кудьрати вә җәбәрүут илгазамәти әң-тәҗгаләнии мин гибәәдикәс-саалихиинәл-ләзиинә ләә хауфүн гәләйһим вә ләә һүм йәхзәнүүн».

«Бисмилләһир-рахманир-рәхим» ның кодрәте белән (Әй Раббым!) данымны күтәр, күкрәгемне киңәйт, эшләремне җиңеләйт, мәрхәмәтең белән миңа тормыш итү өчен кирәкле әйберләрне чиксез итеп бир. «Каф һә йә гайн сад» һәм «Хә мим гайн син каф» хөрмәтенә догаларыбызны кабул ит! Бөеклегең хөрмәтенә мине кыяməттә курыкмаган һәм күңеле төшмәгән колларыңнан ит». (Мәҗмүгатүль-Әхзәб 1/11).

# Ачлык кичермәс өчен укыла торган дога

Аллаһы Тәгалә Нух галәйһиссәламнең тәүбә, гафу һәм ризык турында кылган догасын Коръәндә болай ачыклый: **«Әйтте ки: Раббыгыздан гафу сорагыз, ул, чынлыкта, бөтен нәрсәне гафу итүче. Гафу сорап сүзләремне тыңласагыз, ул (галәмнәрнең Раббысы) сезгә (корылыкны бетереп) күп яңгыр бирәчәк, байлык һәм балалар бирер, сездә бакчалар, елгалар барлыкка килер».**

Нух, 71:10-12

Чыганакларның күбесендә булган Ибне Габбәс радыяллаһу ганһе әйткән хәдистә Аллаһы Расүле болай дигән: «Дәвамлы итеп гафу сораган һәркемнең борчуын Аллаһы сөенечкә, җитешмәгәннәрен муллыкка алыштырып һәм аны өметләнмәгән җирдән ризыкландырыр». (Әбү Давыд: 11/8).

Башка хәдистә Пәйгамбәребез галәйһиссәлам болай дигән: «Вакыйга» сүрәсен һәр көнне укыган кеше беркайчан да ярлы булмас».

# Авырлыгы булган кешенең догасы

Ибне Габбәс радыяллаһу ганһе тапшыруынча, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам авырлык килгәндә болай дип әйтә иде:

لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ الْعَظِيمُ الْحَلِيمُ. لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ رَبُّ الْعَرْشِ الْعَظِيمِ. لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ رَبُّ السَّمَوَاتِ وَ رَبُّ الْأَرْضِ رَبُّ الْعَرْشِ الْكَرِيمِ

«Ләә иләәһә илләллааһүлгазыйм үлхәлим. Ләә иләәһә илләллааһу, раббүль-гаршилгазыйм. Ләә иләәһә илләллаah раббүс-сәмәәвәәти вә раббүләрдый, раббүл-гаршил-газыйм».

«Газим һәм Хәлим булган Аллаһыдан башка илаh юк. Бөек гарешнең Раббысы булган Аллаһыдан башка илаh юктыр. Күкләрнең Раббысыннан, җирнең Раббысыннан һәм кыйммәтле гареш иясе булган Аллаһыдан башка илаh юк». (Бохари, Дәгъват: 123).

# Ачуланганда укыла торган дога

Мөгаз бине Җәбәл радыяллаһу ганһе риваяте буенча: Аллаһы Расүле галәйһиссәламнең янында ике кеше берсе берсен сүгә башладылар. Икесенең берсе бик нык гасабиланды. Хәтта ачуыннан: «Әллә инде борыныма ит кисәге кысылган», – дип уйлый башлады. Расүлуллаh «Мин бер сүз беләм. Әгәр ул кеше ул сүзне әйтсә, ачуы бетәр иде. Ул сүз

أَعُوذُ بِاللهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ

«Әгүүзү билләәһи минәшшәйтаанир-раҗиим», – дип әйтте. (Әбү Давыд: 4780).

# Үлем хәбәре ишеткәннән соң укыла торган дога

Әбү Сәләмә тапшыруы буенча, Аллаh Рәсүле галәйһиссәлам болай дигән: «Берәрегезгә зыян килгәндә болай дисен:

إِنَّا لِلَّهِ وَإِنَّا إِلَيْهِ رَاجِعُونَ ﴿١٥٦﴾

«Иннәә лилләәһи үә иннәә иләйһи рааҗигүүн».

**«Без Аллаһныкы, янә Аллаһка кайтарылачакбыз».**

«Бәкара /Сыер/», 2:156

# Күгәрчен оя корганда

Тыштан тыныч булып күренергә тырышса да, Райнур үзенә үлем якынлашканын аңлады. Палатадашы язучы Галим абыйдан:

– Сез миңа үз-үземне үлемгә әзерләргә ярдәм итә торган берәр төрле китап бирә алмыйсызмы? – диде.

– Монда барысы да аңлаешлы итеп язылган, энекәш, – дип мөгаллим аңа ручка белән кулдан язылган дәфтәр сузды. "Кеше дөньялыкта яшәгәндә байлык җыя, мал туплый. Кайберәүләр хәтта Ахирәткә барасыларын да онытып яшиләр. Ә ул көн һәркемгә килә. Мәрхүмне соңгы юлга туганнары, дуслары озата бара. Гүргә индереп, каберенә туфрак салгач, алар кайтып китә. Кеше дөньялыкта яшәгәндә кылган яхшы һәм начар гамәлләре белән берүзе калып, Аллаһы каршында җавап тота. «Бәндәләр шул чакта тормышның мәгънәсен аңлап яшәмәүләренә бик үкенерләр « диелгән китапларда. Менә болар барысы да безнең дини кануннарны белмәвебездән килә. Чөнки кешеләр дин тоту, динле булу кебек сүзләрдән ни өчендер сагаеп калалар,шомланалар төсле. Шуңамы, мәктәптә дин белеме укытылмый, Ислам мәдәнияте өйрәтелми.

Югыйсә, Ислам өйрәтмәләре үзе бер университет бит. Динле булуны иманлы булу дип аңламыйбызмы? Дин белән иман сүзе янәшә тора. Ә иман әхлакне, намусны, ышанычны, тугрылыкны, вәгъдәле булуны белдерә. Бездә «вәгъдә – иман», дигән гыйбрәтле төшенчә бар. Ә вәгъдәсез кешене имансыз кешегә тиңләгәннәр. Фәнис Ярулинның Ринат Галиевка багышланган бу турыда хәтта шигыре дә бар:

Яманлыкны күрми башлар идек,
Әзме аңа күнегеп беткәннәр –
Ярый әле табылып тора җирдә
Күңелендә иман йөрткәннәр, –

дип яза ул.

Шулай булгач, динле һәм иманлы, ягъни вәгъдәле, ихлас дигән сүз. Рәхимле һәм намуслы булудан куркырга кирәкми. Иманы нык булган кеше усаллыктан, рухи түбәнлектән, кыргыйлыктан, әхлаксыз гамәлләр эшләүдән ерак тора. Ислам галиме Сәид Нурсиның бик гыйбрәтле мондый сүзләре бар: "Вөҗданның зыялыгы дин гыйлемнәре белән, ә акылның нуры фән гыйлемнәре белән яктыртылыр. Икесенең бергә берләшүеннән акылда һәм күңелдә хакыйкать барлыкка килер. Әгәр дин гыйлеме үзе генә укытылса, фанатизм барлыкка килә, фән гыйлеме генә укытылса, иман хакыйкатьләреннән шикләнү һәм бик күп начарлыклар туа. Киләчәктә уку йортларында дин һәм фән гыйлемнәре бергә укытылсын», – дигән. Мондагы сүзләрнең хаклыгын бүгенге тормышыбыз дәлилләп, раслап тора. Бүгенге әхлаксызлык, бозыклык, рәхимсез мөнәсәбәт, фахишәлек, исереклек иман хакыйкатьләренә шикләнеп караудан, ышанмаудан килә. Ә ышаныч юлы, таяныр терәк – Коръән кушканча яшәү. Яшьләребез шушы юлга чыга алмыйча, мәгънәле һәм матур тормышка өметләрен югалта барып, наркоманлык, бозыклык юлына китә. Чөнки начар нәрсә тизрәк кабул ителә. Мәктәптә балаларга түбән сыйныфтан ук ислам әхлагы өйрәтелсә, аларның рухлары нык булыр, күңелләренә бозык хисләр салына алмас иде.

Укытучыларыбызга файдаланыр өчен әзер китап та бар. Халкыбызны бертуктаусыз иманга, гыйлемгә өндәп яшәгән галимнәребез арасында, фикерләренең тирәнлеге, фәлсәфилеге белән сокландырган, иман юлында нык торып, милләтебезгә хезмәт иткән олуг остазыбыз Риза Фәхретдиннең «Җәвамигуль кәлим шәрхе « китабы, балаларыбызга әхлак тәрбиясе бирүдә дә ярдәмлек безнең өчен. Татар дөньясында тиңе булмаган, рухи хәзинә булып саналган әлеге китап 1917нче елдан бүгенге көнгә кадәр гарәп илләре уку йортларында дәреслек итеп укытыла. Ниһаять, 1995нче елда ул кириллица хәрефләре белән татар телендә дә басылып чыкты. Бу гаҗәеп хезмәтендә күренекле философ Рәсүлебезнең хакыйкый хәдисләрен тирән һәм оста итеп шәрехләп бирә. Китапны пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм безнең өчен калдырган дөрес яшәү кагыйдәләре дип тә аңларга була. Шушы китабында Р.Фәхретдин педагогик, иҗтимагый, әхлакый мәсьәләләрне күтәрә. Укучының яшәү мәгънәсе турындагы фикерләрен тирәнәйтә, тормыш авырлыкларын җиңеләйтергә, бозык теләкләрне юкка чыгарырга, төшенке күңелләргә шатлык китерергә, рухны сафландырырга ярдәм итә. Балаларыбызны тәүфыйкълы, әдәпле һәм мәрхәмәтле итеп күрергә теләсәк, бу китап белән һәрберебез танышырга, аны укып өйрәнергә тиешбез.

Бу шулкадәр зур көчкә ия китап ки, андагы фикерне аңыбызга урнаштыра алсак, без бәхетлерәк, сәламәтрәк яшәрбез. Харам хисләр күңелебездән китәр, бер-беребезгә мөнәсәбәтебез җылыныр, сабырлыгыбыз артыр, һәркем уйланыр. Кемнәрдер буш сүз сөйләп гомер уздыруларын аңлар һәм башка мәгънәле фикерләр белән акылын баетыр. Китаптагы кайбер хәдисләр белән таныштырып китәргә дә кирәктер.

1. Икейөзлелек галәмәте өчтер: икейөзле кеше сүз сөйләсә – ялганлар, вәгъдә бирсә сүзендә тормас, үзенә тапшырылган әманәткә хыянәт итәр. Ялган сөйләү күңел бозыклыгыннан килә. Кешеләр аңа күбрәк яшь вакытларында өйрәнәләр. Соңыннан күңелләрендә гадәт булып урнашып кала (бу хәдис телне яшьтән ук ялганнан сакларга өйрәтә).

2. Иң кечкенә бер изгелекне дә кадерсез санама вә игътибарсыз калдырма. Суга килүченең чиләгенә су алып салуың да бер изгелектер (изгелекнең кадерен югалтмаска чакыра).

3. Дустыңны сөюеңне саклык белән алып бар, бәлки ул беркөн сиңа дошман булыр; дошманыңны дошман күрүеңне дә саклык белән алып бар, бәлки ул беркөн сиңа дус булыр.

4. Арттыру белән мактаучыларның йөзләренә туфрак сибегез (чөнки артык макталган кеше ул бик тиз зураеп китә).

5. Яхшы эшләреӊ сине шатландырса, бозык эшләреӊ кайгыга салса, син чын адәмсеӊ (уйлап карасаӊ, бик тирән мәгънә, әхлак-әдәп ята монда).

6. Ахмак кеше белән мөнәсәбәт ясама. «Ахмак дуска караганда, акыллы дошман яхшырак « дигән сүз күп тәҗрибәләрдән соң әйтелгән. Ахмактан файда көтү аяз күктән яӊгыр көтү кебек мәгънәсез бер эштер.

7. Адәмнәрнеӊ иманы камил булганы – холыклары гүзәл булганнарыдыр. Гүзәл холыклы кеше үз гаиләсенә дә, башкаларга да мөмкин кадәр изгелек кыла".

"Узган гомер турында уйланып, артка – үткәннәргә әйләнеп карыйсыӊ да, аныӊ инде кире әйләнеп кайтмаячагына тагын бер кат инанып, бераз гына уфтанып та куясыӊ. Ул, әйтерсеӊ лә, бер мизгел кебек кенә үтеп киткән. Әйе, әгәр кеше үлемсез булса, бәлки ул вакытны да исәпләмәс, узган гомерен дә җәлләмәс иде. Ләкин барыбыз да, кайчан да булса үләчәк, ягъни мәӊгелек дөньяга күчәчәк бит. Инде кайбер вафат булган кешеләрне искә алып, үзебезгә үзебез бәя бирәбез: "Әнә теге кеше кыска гына гомер эчендә нинди шәхескә әверелде һәм калган буынга онытылмаслык мирас калдырды... "Димәк, үлем безне һәрбер минутны, сәгатьне, көнне бушка уздырмаска да өйрәтә. Кеше гомере буе хыялланып, матур уйлар белән янып яшәргә тиештер ул. "Хыялсыз кеше – сүнгән кеше», – дип тикмәгә генә әйтмиләр бит. Шул уйхыялларны тормышка ашыру өчен көрәшә белергә дә кирәк. Төшенкелеккә бирелеп, миннән барыбер булмый, дип тормышның кызыгын бетерү өчен күп кирәк микән? Язмыш дигәне дә адәм баласын төрлечә сыный. Әнә, мисал өчен танылган язучыбыз Фәнис Яруллин да бәхетсез очрак нәтиҗәсендә, яшьяшь килеш урын өстенә егылган. Әмма ничек кенә авыр булса да, рухын, яшәү дәртен сүндермәгән, ул үзендә нindидер могҗизалы көч, сәләт таба алган. Ярым хәрәкәтсез хәлдә ятып та, күпме әсәр, безнең өчен тиңсез хәзинә иҗат иткән. Ә бит бу тормышта юк кына сәбәпләрдән дә төшенкелеккә бирелеп, үз-үзләренә кул салучылар да бар. Аларның күпчелеге – яшьләр. Аллаһы ихтыяры белән дөньяга килгәнсең икән, дөрес юлны сайлап, яшәргә дә, яшәргә бит, югыйсә. Әлбәттә, иман китергән, Ислам кагыйдәләрен вә хөкемнәрен яхшы аңлаган бәндәләр бу хаталыклардан ерак торырлар. Дин беркайчан да юньсезгә өйрәтми. Дөрес, кеше аңа бик авырлык белән тартыла. Ләкин бер аңлагач, ул инде аңа гомере буе тугры булып кала. Әйе, безнең һәр үткән көнебез, аебыз, елыбыз – үлемгә таба бер адымыбыз ул. Әмма әҗәл артында Җәннәт белән Җәһәннәм тора. Бер адым атлаган саен, аларның кайсына таба якынаябыз икән соң? Яхшы гамәлләр кылып яшәгән кешеләрнең күңелләре саф, ниятләре изге була. Андыйлар, әлбәттә, җәннәт бакчаларында хозурланырлар. Ә инде Аллаһы тарафыннан бүләк итеп бирелгән гомерләрен заяга үткәргән, күңелләрен харамга салган кешеләр Ахирәт тормышларында мең төрле газапка дучар ителәләр.

Ураза тоту, намаз уку – ул бер бәхет, бер сәгадәт, Аллаһының безгә биргән бүләге. Аллаһы Раббыбыз кар- шысындагы вазифаларыбызны үтәүчеләрдән булып, гыйбадәтебезне күбрәк кылыйк, үткән гомеребездәге хилаф эшләребезгә тәүбә итик, һәм ул үзенең әҗер-савапларын безгә ирештерер, үлгәннән соң, шушы гыйбадәтләребез өчен, җәннәте белән сөендерер".

Эш белән алданып яшәп, ахирәткә күчәсемне уйлап та караганым булмады. Сез моны китап итеп чыгарыгыз, минем кебек кешеләргә ярдәм итәр өчен..., – диде Райнур, дәфтәрне язучыга биргәндә...

■ **Гөлсинә Галимуллинаның «Күгәрчен оя корганда» китабыннан өзек**

# «АЗАН» РАДИОСЫ ТАПШЫРУЛАРЫ ҖӘДВӘЛЕ

«Безне radioazan.ru сайтында яки Play Market һәм App Store'дан йөкләп алынган «Азан» радиосы рәсми кушымталары аша тыңлагыз».

**ДҮШӘМБЕ, СИШӘМБЕ, ЧӘРШӘМБЕ, ПӘНҖЕШӘМБЕ**

| | |
|---|---|
| 0:00-5:59 | Коръән |
| 6:00-6:20 | Коръән тәфсире |
| 6:30-6:32 | Көндәлек догалар |
| 6:40-6:50 | Таян Аллаһка |
| 6:55-7:00 | Хәзрәткә сорау |
| 7:05-7:15 | Иман тәме |
| 7:20-7:23 | Миллият сүзлеге |
| 7:30-7:35 | Гыйбрәтле кыйссалар |
| 7:40-7:45 | Анонслар |
| 7:50-8:05 | Актуаль тапшыру |
| 8:10-8:17 | Шәхесләргә шәрехләр |
| 8:25-8:40 | Сак булыгыз! Секталар! |
| 8:50-8:55 | Үземә кайту |
| 9:00-9:15 | Күңелдән күңелгә |
| 9:25-9:35 | Тынычлык тәгълимате |
| 9:45-9:55 | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) |
| 10:00-10:15 | Бәхет тулы йорт |
| 10:20-10:25 | Гыйбадәттә сәгадәт |
| 10:30-10:45 | 101 вәгазь |
| 10:55-10:57 | Көндәлек догалар |
| 11:00-11:15 | 40 хәдис |
| 11:25-11:28 | Миллият сүзлеге |
| 11:40-11:50 | Намаз дәресләре |
| 12:00-12:04 | Азан |
| 12:04-12:04 | Хәдис |
| 12:10-12:20 | Хикәятләр илендә |
| 12:30-12:40 | Пәйгамбәрләр тарихы |
| 12:50-12:57 | Мәчетләребез тарихы |
| 13:00-13:10 | Сөннәт юлы |
| 13:15-13:20 | Анонслар |
| 13:25-13:40 | Әбү Хәнифә (р.г.) |
| 13:45-13:50 | Хәзрәткә сорау |
| 14:00-14:05 | Әхлак баскычлары |
| 14:10-14:20 | Тынычлык тәгълимате |
| 14:30-14:35 | Үземә кайту |
| 14:45-14:48 | Миллият сүзлеге |
| 15:00-15:20 | Коръән тәфсире |
| 15:30-15:32 | Көндәлек догалар |
| 15:40-15:50 | Таян Аллаһка |
| 15:55-16:00 | Хәзрәткә сорау |
| 16:05-16:15 | Иман тәме |
| 16:20-16:23 | Миллият сүзлеге |
| 16:30-16:35 | Гыйбрәтле кыйссалар |
| 16:40-16:45 | Анонслар |
| 16:50-17:05 | Актуаль тапшыру |
| 17:10-17:17 | Шәхесләргә шәрехләр |
| 17:25-17:40 | Сак булыгыз! Секталар! |
| 17:50-17:55 | Үземә кайту |
| 18:00-18:15 | Күңелдән күңелгә |
| 18:25-18:35 | Тынычлык тәгълимате |
| 18:45-18:55 | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) |
| 19:00-19:15 | Бәхет тулы йорт |
| 19:20-19:25 | Гыйбадәттә сәгадәт |
| 19:30-19:45 | 101 вәгазь |
| 19:55-19:57 | Көндәлек догалар |
| 20:00-20:15 | 40 хәдис |
| 20:25-20:28 | Миллият сүзлеге |
| 20:40-20:50 | Намаз дәресләре |
| 21:00-21:00 | Хәдис |
| 21:05-21:08 | Нәниләргә нәсыйхәт |
| 21:10-21:20 | Хикәятләр илендә |
| 21:30-21:40 | Пәйгамбәрләр тарихы |
| 21:50-21:57 | Мәчетләребез тарихы |
| 22:00-22:10 | Сөннәт юлы |
| 22:15-22:20 | Анонслар |
| 22:25-22:40 | Әбү Хәнифә (р.г.) |
| 22:45-22:50 | Әхлак баскычлары |
| 22:55-22:58 | Миллият сүзлеге |
| 23:00-5:59 | Коръән |


**ҖОМГА**

| | |
|---|---|
| 0:00-5:59 | Коръән |
| 6:00-6:20 | Коръән тәфсире |
| 6:30-6:32 | Көндәлек догалар |
| 6:40-6:50 | Таян Аллаһка |
| 6:55-7:00 | Җомга тәбриге |
| 7:05-7:15 | Иман тәме |
| 7:20-7:23 | Миллият сүзлеге |
| 7:30-7:35 | Гыйбрәтле кыйссалар |
| 7:40-7:45 | Анонслар |
| 7:50-8:05 | Актуаль тапшыру |
| 8:10-8:17 | Шәхесләргә шәрехләр |
| 8:25-8:40 | Сак булыгыз! Секталар! |
| 8:50-8:55 | Үземә кайту |
| 9:00-9:15 | Күңелдән күңелгә |
| 9:25-9:35 | Тынычлык тәгълимате |
| 9:45-9:55 | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) |
| 10:00-10:15 | Бәхет тулы йорт |
| 10:20-10:25 | Гыйбадәттә сәгадәт |
| 10:30-10:45 | 101 вәгазь |
| 10:55-10:57 | Көндәлек догалар |
| 11:00-11:15 | 40 хәдис |
| 11:25-11:28 | Миллият сүзлеге |
| 11:30-11:35 | Җомга тәбриге |
| 11:40-11:50 | Намаз дәресләре |
| 12:00-12:04 | Азан |
| 12:04-12:04 | Хәдис |
| 12:10-12:20 | Хикәятләр илендә |
| 12:30-12:40 | Пәйгамбәрләр тарихы |
| 12:50-12:57 | Мәчетләребез тарихы |
| 13:00-13:10 | Сөннәт юлы |
| 13:15-13:20 | Анонслар |
| 13:25-13:40 | Әбү Хәнифә (р.г.) |
| 13:45-13:50 | Җомга тәбриге |
| 14:00-14:05 | Әхлак баскычлары |
| 14:10-14:20 | Тынычлык тәгълимате |
| 14:30-14:35 | Үземә кайту |
| 14:45-14:48 | Миллият сүзлеге |
| 15:00-15:20 | Коръән тәфсире |
| 15:30-15:32 | Көндәлек догалар |
| 15:40-15:50 | Таян Аллаһка |
| 15:55-16:00 | Хәзрәткә сорау |
| 16:05-16:15 | Иман тәме |
| 16:20-16:23 | Миллият сүзлеге |
| 16:30-16:35 | Гыйбрәтле кыйссалар |
| 16:40-16:45 | Анонслар |
| 16:50-17:05 | Актуаль тапшыру |
| 17:10-17:17 | Шәхесләргә шәрехләр |
| 17:25-17:40 | Сак булыгыз! Секталар! |
| 17:50-17:55 | Үземә кайту |
| 18:00-18:15 | Күңелдән күңелгә |
| 18:25-18:35 | Тынычлык тәгълимате |
| 18:45-18:55 | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) |
| 19:00-19:15 | Бәхет тулы йорт |
| 19:20-19:25 | Гыйбадәттә сәгадәт |
| 19:30-19:45 | 101 вәгазь |
| 19:55-19:57 | Көндәлек догалар |
| 20:00-20:15 | 40 хәдис |
| 20:25-20:28 | Миллият сүзлеге |
| 20:40-20:50 | Намаз дәресләре |
| 21:00-21:00 | Хәдис |
| 21:05-21:08 | Нәниләргә нәсыйхәт |
| 21:10-21:20 | Хикәятләр илендә |
| 21:30-21:40 | Пәйгамбәрләр тарихы |
| 21:50-21:57 | Мәчетләребез тарихы |
| 22:00-22:10 | Сөннәт юлы |
| 22:15-22:20 | Анонслар |
| 22:25-22:40 | Әбү Хәнифә (р.г.) |
| 22:45-22:50 | Әхлак баскычлары |
| 22:55-22:58 | Миллият сүзлеге |
| 23:00-5:59 | Коръән |

**ШИМБӘ, ЯКШӘМБЕ**

| | |
|---|---|
| 0:00-5:59 | Коръән |
| 6:00-6:20 | Коръән тәфсире |
| 6:30-6:32 | Көндәлек догалар |
| 6:40-6:50 | Таян Аллаһка |
| 6:55-7:00 | Хәзрәткә сорау |
| 7:05-7:15 | Иман тәме |
| 7:20-7:23 | Миллият сүзлеге |
| 7:30-7:35 | Гыйбрәтле кыйссалар |
| 7:40-7:45 | Анонслар |
| 7:50-8:05 | Миһербанлы җаннар |
| 8:10-8:17 | Шәхесләргә шәрехләр |
| 8:25-8:40 | Сак булыгыз! Секталар! |
| 8:50-8:55 | Үземә кайту |
| 9:00-9:15 | Күңелдән күңелгә |
| 9:25-9:35 | Тынычлык тәгълимате |
| 9:45-9:55 | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) |
| 10:00-10:15 | Бәхет тулы йорт |
| 10:20-10:25 | Гыйбадәттә сәгадәт |
| 10:30-10:45 | 101 вәгазь |
| 10:55-10:57 | Көндәлек догалар |
| 11:00-11:15 | 40 хәдис |
| 11:25-11:28 | Миллият сүзлеге |
| 11:40-11:50 | Намаз дәресләре |
| 12:00-12:04 | Азан |
| 12:04-12:04 | Хәдис |
| 12:10-12:20 | Хикәятләр илендә |
| 12:30-12:40 | Пәйгамбәрләр тарихы |
| 12:50-12:57 | Мәчетләребез тарихы |
| 13:00-13:10 | Сөннәт юлы |
| 13:15-13:20 | Анонслар |
| 13:25-13:40 | Миһербанлы җаннар |
| 13:45-13:50 | Хәзрәткә сорау |
| 14:00-14:05 | Әхлак баскычлары |
| 14:10-14:20 | Тынычлык тәгълимате |
| 14:30-14:35 | Үземә кайту |
| 14:45-14:48 | Миллият сүзлеге |
| 15:00-15:20 | Коръән тәфсире |
| 15:30-15:32 | Көндәлек догалар |
| 15:40-15:50 | Таян Аллаһка |
| 15:55-16:00 | Хәзрәткә сорау |
| 16:05-16:15 | Иман тәме |
| 16:20-16:23 | Миллият сүзлеге |
| 16:30-16:35 | Гыйбрәтле кыйссалар |
| 16:40-16:45 | Анонслар |
| 16:50-17:05 | Миһербанлы җаннар |
| 17:10-17:17 | Шәхесләргә шәрехләр |
| 17:25-17:40 | Сак булыгыз! Секталар! |
| 17:50-17:55 | Үземә кайту |
| 18:00-18:15 | Күңелдән күңелгә |
| 18:25-18:35 | Тынычлык тәгълимате |
| 18:45-18:55 | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) |
| 19:00-19:15 | Бәхет тулы йорт |
| 19:20-19:25 | Гыйбадәттә сәгадәт |
| 19:30-19:45 | 101 вәгазь |
| 19:55-19:57 | Көндәлек догалар |
| 20:00-20:15 | 40 хәдис |
| 20:25-20:28 | Миллият сүзлеге |
| 20:40-20:50 | Намаз дәресләре |
| 21:00-21:00 | Хәдис |
| 21:05-21:08 | Нәниләргә нәсыйхәт |
| 21:10-21:20 | Хикәятләр илендә |
| 21:30-21:40 | Пәйгамбәрләр тарихы |
| 21:50-21:57 | Мәчетләребез тарихы |
| 22:00-22:10 | Сөннәт юлы |
| 22:15-22:20 | Анонслар |
| 22:25-22:40 | Миһербанлы җаннар |
| 22:45-22:50 | Әхлак баскычлары |
| 22:55-22:58 | Миллият сүзлеге |
| 23:00-5:59 | Коръән |

*Җәдвәлдә 10-15 минутлык үзгәрешләр булырга мөмкин.*




## Коръәннең татар теленә тәрҗемәсе дөнья күрде

«Хозур» нәшрият йорты ТР мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан әзерләнгән «Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә» басмасы – Коръәннең татар теленә тәрҗемәсен нәшер итте.

Башка тәфсирләрдән аермалы буларак әлеге хезмәт – тел белгечләре, имамнар һәм мәдрәсә укытучыларының берләшеп башкарган җиде еллык хезмәт нәтиҗәсе. Изге Китапка тәфсир әзерләгәндә имам Әл-Мәхәлли һәм Әс-Суютыйның «Тәфсир Әл-Җәләләйн» һәм шәех Мәхмүд Әл-Уфи «Коръән Мәҗид» хезмәтләренә таянылды.

Шулай ук эш барышында Ногмани, Мөхәммәт Садыйк бине Шаһ Әхмәт Иманколый Казанины «Тәсһилул-бәйән», Шәйхел-ислам бине Әсәдулла Хәмидинең «Әл-Иткан» тәфсирләренә, шулай ук төрле гасырларда яшәгән Әт-Табәри, Әл-Матури-ди, Ибне Кәсир, Әл-Куртуби, Ән-Нәсәфи, Алуси кебек авторларның дан казанган тәфсирләренә дә мөрәҗәгать ителде.

- **Кибетләрнең адреслары:**
- Тукай урамы, 36 йорт;
- Газовая урамы, 14 йорт (склад).

- **Белешмәләр өчен телефон:**
+7 (903) 388-86-33

**9.11**
**Мәүлид Ән-Нәби**

islamtoday ALL ABOUT MUSLIM WORLD

# Иншалар бәйгесе

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә булган яратуыгызны ничек белдерер идегез?

**Иҗади хезмәтләр:**

14 нче октябрьдән 6 нче ноябрьгә кадәр, islam_today@mail.ru почтасына кабул ителә.

**КАЗАН ӨЧЕН НОЯБРЬ АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ**

| Көн | Иртәнге намаз | | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | | | | | |
| 01.11.2019 | 04:42 | 05:18 | 06:48 | 12:00 | 14:11 | 16:04 | 17:49 |
| 02.11.2019 | 04:44 | 05:20 | 06:50 | 12:00 | 14:09 | 16:02 | 17:47 |
| 03.11.2019 | 04:46 | 05:22 | 06:52 | 12:00 | 14:07 | 16:00 | 17:45 |
| 04.11.2019 | 04:48 | 05:24 | 06:54 | 12:00 | 14:05 | 15:58 | 17:43 |
| 05.11.2019 | 04:49 | 05:26 | 06:56 | 12:00 | 14:04 | 15:56 | 17:41 |
| 06.11.2019 | 04:51 | 05:29 | 06:59 | 12:00 | 14:02 | 15:54 | 17:40 |
| 07.11.2019 | 04:53 | 05:31 | 07:01 | 12:00 | 14:00 | 15:52 | 17:38 |
| 08.11.2019 | 04:55 | 05:33 | 07:03 | 12:00 | 13:58 | 15:50 | 17:36 |
| 09.11.2019 | 04:56 | 05:35 | 07:05 | 12:00 | 13:56 | 15:48 | 17:35 |
| 10.11.2019 | 04:58 | 05:37 | 07:07 | 12:00 | 13:55 | 15:46 | 17:33 |
| 11.11.2019 | 05:00 | 05:39 | 07:09 | 12:00 | 13:53 | 15:44 | 17:32 |
| 12.11.2019 | 05:02 | 05:41 | 07:11 | 12:00 | 13:51 | 15:42 | 17:30 |
| 13.11.2019 | 05:03 | 05:43 | 07:13 | 12:00 | 13:50 | 15:41 | 17:29 |
| 14.11.2019 | 05:05 | 05:45 | 07:15 | 12:00 | 13:48 | 15:39 | 17:27 |
| 15.11.2019 | 05:07 | 05:47 | 07:17 | 12:00 | 13:46 | 15:37 | 17:26 |
| 16.11.2019 | 05:08 | 05:49 | 07:19 | 12:00 | 13:45 | 15:35 | 17:25 |
| 17.11.2019 | 05:10 | 05:51 | 07:21 | 12:00 | 13:43 | 15:34 | 17:23 |
| 18.11.2019 | 05:12 | 05:53 | 07:23 | 12:00 | 13:42 | 15:32 | 17:22 |
| 19.11.2019 | 05:13 | 05:55 | 07:25 | 12:00 | 13:41 | 15:31 | 17:21 |
| 20.11.2019 | 05:15 | 05:57 | 07:27 | 12:00 | 13:39 | 15:29 | 17:20 |
| 21.11.2019 | 05:16 | 05:59 | 07:29 | 12:00 | 13:38 | 15:28 | 17:19 |
| 22.11.2019 | 05:18 | 06:01 | 07:31 | 12:00 | 13:37 | 15:26 | 17:18 |
| 23.11.2019 | 05:19 | 06:03 | 07:33 | 12:00 | 13:35 | 15:25 | 17:17 |
| 24.11.2019 | 05:21 | 06:05 | 07:35 | 12:00 | 13:34 | 15:24 | 17:16 |
| 25.11.2019 | 05:22 | 06:07 | 07:37 | 12:00 | 13:33 | 15:22 | 17:15 |
| 26.11.2019 | 05:24 | 06:09 | 07:39 | 12:00 | 13:32 | 15:21 | 17:14 |
| 27.11.2019 | 05:25 | 06:11 | 07:41 | 12:00 | 13:31 | 15:20 | 17:13 |
| 28.11.2019 | 05:27 | 06:12 | 07:42 | 12:00 | 13:30 | 15:19 | 17:13 |
| 29.11.2019 | 05:28 | 06:14 | 07:44 | 12:00 | 13:29 | 15:18 | 17:12 |
| 30.11.2019 | 05:29 | 06:16 | 07:46 | 12:00 | 13:28 | 15:17 | 17:11 |

**ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ**
*Октябрь саны, №10 (291)*

Баш мөхәррир: **Нәширбанов И.К.**
Мөхәррир: **Хамматов Л. Р.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Сәйфетдияров Р. Г.**
**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur.ru
**Телефон:** +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
**Камил СӘМИГУЛЛИН;**
«Хозур» нәшрият йорты директоры
**Ришат ХӘМИДУЛЛИН;**
ТР МДНнең дәгъват бүлеге җитәкчесе
**Булат МӨБӘРӘКОВ;**
Татарстанның баш казые
**Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы
**Габдулла ӘДҺӘМОВ**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**Нәшир:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә Заказ №2754
Газетага ярты елга язылу бәясе – 132 сум. Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 22 нче октябрьдә таратыла.
График буенча бу санга 21 нче октябрь көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.